**КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ
МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИУТЫ
*Гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы*

Р.Р.Сәлахова

# СӘНГАТЬ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ

Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы

Казан - 2016

**Сәлахова Р.Р.**
**Сәнгать өлкәсендә татар теле:** Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы / Р.Р. Сәлахова. – Казан, 2016. – 96 б.

*Фәнни мөхәррир –*
Р.Р.Җамалетдинов, филология фәннәре докторы, профессор

*Рецензентлар:*
филология фәннәре кандидаты, доцент З.Н. Кириллова
филология фәннәре кандидаты, доцент Г.Ф. Зиннәтуллина

Кулланма югары уку йортларының сәнгать бүлегендә белем алучы студентларга юнәлдерелгән. Хезмәттәге һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмияткә ия булган текстлар һөнәри компетенцияне формалаштыру максатын күздә тотып тәкъдим ителде. Текст белән бәйле биремнәр, тестлар студентларга булачак һөнәрләре белән бәйле материалның лингвистик аспектларын үзләштерергә ярдәм итәчәк. Кулланма ике кисәктән тора. Беренче кисәктә сынлы сәнгать турындагы текстлар урын алды һәм ул "Дизайн" белгечлеген үзләштерүче студентларга тәкъдим ителә.

Лев Толстой исемендәге
филология һәм мәдәниятара багланышлар
институты укыту методик советы
(10 нчы номерлы беркетмә, 12 нче май, 2016 нчы ел)

© Казан федераль университеты, 2016
© Сәлахова Р.Р., 2016

# КЕРЕШ

Һөнәри белем бирә торган югары уку йортларында “Татар телендә һөнәри багланышлар” (“Татарский язык в профессиональной коммуникации») фәне студентларның татар телендә үз һөнәренә бәйле булган барлык мәгълүматны тиешле дәрәҗәдә аңлый һәм аңлата белүенә, һөнәр үзләштерү юлында аннан иҗади файдалана алуына корылган.

Аралашу ихтыяҗы булдыру, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни мәгълүмат туплау өчен, “Татар телендә һөнәри багланышлар” дәресләрендә кулланылган иң уңышлы алымнарның берсе – текстлар белән эш. Текст эчтәлегенең студент сайлаган һөнәр белән бәйле булуы бик мөһим, чөнки студент югары һөнәри белем бирү уку йортына билгеле бер һөнәр үзләштерү өчен укырга керә һәм булачак һөнәре белән бәйле теләсә нинди мәгълүмат анда кызыксыну уятырга сәләтле. “Дизайн” белгечлеген үзләштерүче студентларга атап төзелгән әлеге кулланмада, мәсәлән, сәнгать өлкәсен, аерым алганда, татар сәнгатен яктырткан текстлар бирелде. Һәр текст ахырында ике юнәлештәге биремнәр комплексы бар. Аларның бер төрләре татар теленең лексик, грамматик берәмлекләре белән эшләүгә юнәлдерелгән булса, икенчеләре турыдан-туры текстның эчтәлегенә бәйле. Биредә студентка тексттагы иң әһәмиятле мәгълүматны сайлап ала белү, тектның эчтәлегеннән чыгып, аңа исем уйлап табу, текстны тулыландыру, яки тексттагы терминнарга билгеләмә бирү, текст буенча сораулар әзерләү яки, киресенчә, җавап бирү һ.б.ш. биремнәр һәм күнегүләр тәкъдим ителә. Алар арасында тексттагы аерым фактларны конкретлаштыру, аларга бәя бирү, тексттагы фактлар белән килешү яки килешмәвеңне белдерү кебек текст эчендәге мәгълүматны сөйләмдә уңышлы куллана алуга корылганнары да бар. Гомумән алганда, әлеге биремнәр һөнәри сөйләм күнекмәләрен формалаштыруга, сөйләмне, төгәлрәге, һөнәри сөйләмне камилләштерүгә юнәлдерелгәннәр. Теге яки бу текстка яки аның эчтәлегендәге аерым бер фактка нигезләнеп, тексттагы сөйләм берәмлекләрен уңышлы кулланып, студент үзенең

фикерен белдерә ала икән, димәк, һөнәри сөйләм биреме үтәлде дигән сүз.

Һөнәри белем алучы студентлар үзләштерә торган белгечлекләре белән бәйле булган төп терминнарны да яхшы белергә тиеш. Аерым бер өлкәне чагылдырган текстларда шул өлкә белән бәйле терминнарның күп булуы гаҗәп түгел. Сәнгать өлкәсенә караган текстларда, мәсәлән, иң әһәмиятле тел берәмлекләре булып сәнгать терминнары тора. Студент тексттан үз белгечлеге белән бәйле терминнарны табып, аларга татар телендә билгеләмә бирә белергә, аларның мәгънәләрен аңлап эш итәргә тиеш. Терминнарның татарча-русча атамаларын өйрәнүгә дә зур игътибар сорала. Булачак һөнәре өлкәсендәге күпсанлы терминнарның ике телдә яңгырашын өйрәнү студентларга фәнни планда гына түгел, гомумән, дөньяны танып белү юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк. Кулланмада тәкъдим ителгән сүзлекчә шул максатны күздә тотып бирелде.

БЕРЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ СЫНЛЫ СӘНГАТЕ

1. Татар халкының сынлы сәнгате тарихы.
2. Сынлы сәнгать төрләре.
3. Татар халкының сынлы сәнгать осталары.
4. Татарстан Республикасының дәүләт сынлы сәнгать музее.

Татарстан территориясендә төрле кабиләләр каберләреннән табылган әйберләр иң борынгы сәнгать *ядкәрләре* булып санала. 8 йөздән алып урта гасырлар башындагы сәнгатьнең үсеш дәрәҗәсен Идел буе Болгар дәүләте шәһәр, авыл каберлекләреннән чыккан археологик табылдыклар күрсәтә. Ислам динен кабул иткәннән соң, Болгар дәүләтендә мәдәният *шәригать* кануннарына буйсына: бүтән мөселман халыклары сәнгате шикелле үк, сынлы сәнгать орнаментка таянган *гамәли* бизәлеш һәм архитектура сәнгате белән чикләнә. Болгарда шәһәр мәдәнияте бик нык алга киткән була, милли сәнгатьнең юнәлешен әнә шул билгели, бу исә Идел буе һәм Көньяк Урал буендагы башка халыкларның сәнгатьчә фикерләвенә дә зур йогынты ясый.

Татарстан территориясендәге сәнгать тарихында Алтын Урда дәвере аерым урын алып тора. Аның үсешендәге үзенчәлекне этник *күпкырлылык* – бер яктан, кыпчакларның күчмә, икенче яктан, болгарларның *утрак мәдәнияте* элементлары билгели. Аңа *шәригать* кысаларында үскән орнамент төрлелеге, төсләрне мул куллану, *зиннәтлелек* хас. Кием-салымны, металлга бизәкләр төшерү, зәркәнчелек һәм балчыкны яндырып әйбер ясауда Алтын Урда сәнгате стиле нык чагыла. Казан ханлыгында сәнгатьнең монументаль-гамәли һәм нәфис һөнәрчелек төрләре уңышлы дәвам итә.

Казан арты төбәге татар милли сәнгатенең үзәгенә әверелә. 18 йөзнең икенче яртысыннан Казанның татар халкы яшәгән

өлешендә һөнәрчелек яңадан көчәя, традицион милли сәнгать төрләре тернәкләнеп китә. Гамәли бизәлеш сәнгате төрләреннән орнамент, каюлы күн чигү, укалап чигү, тукучылык, хаттатчылык, милли киемнәр тегү, өйләрнең эчен бизәү үзенчәлекле төс ала.

19 йөз ахыры – 20 йөз башында татар халкының профессиональ милли сынлы сәнгате барлыкка килә, үз рәссамнары үсеп чыга: Ш.Таһиров, М.Идрисев, М.Байкиев, Г.Акчурина, К.Дәүләткилдиев һ.б. Алар нәкыш, графика һәм театр сәхнәләрен бизәү белән *мәшгуль була*. Татарстанда сынлы сәнгать үсешенә Казан сәнгать мәктәбе зур өлеш кертә. Нәкыш осталары: Н.Фешин, Б.Урманче, П.Беньков, В.Тимофеев, һ.б.; графика осталары: Ф.Таһиров, Г.Арсланов, Ш.Мөхәммәтҗанов, Н.Шикалов, К.Чеботарев һ.б.; Скульптура өлкәсендә: В.Богатырев, С.Ахун таныла.

20 йөзнең икенче яртысында нәкыш өлкәсендә Х.Якупов, Л.Фәттахов, К.Максимов, Н.Кузнецов, В.Кудelькин, Ш.Шәйдуллин, А.Абызгилдин, К.Нәфыйков, И.Зарипов, **И.Рәфыйков**, Р.Госманов һ.б.; графикада Г.Рахманкулова, Э.Ситдыйков, **Т.Хаҗиәхмәтов**, Э.Зарипов; скульптурада В.Маликов, **Р.Нигъмәтуллина**, Н.Адылов, Ф.Фәсхетдинов һ.б.; театр сәхнәсен бизәүдә П.Сперанский, М.Сүтүшев, Э.Гельмс, **Ә.Тумашев** һ.б.; гамәли һәм монументаль бизәлеш сәнгатендә В.Федоров, **Р. Сафиуллин**, Б. Шубин һ.б. зур уңышларга ирешәләр. Бу дәвердә жанр һәм стиль төрләре арта, яңа иҗади юнәлешләр пәйда була, татар милли сәнгате үсеш ала (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Сораулар.**

1. Татар сәнгатенең борынгы чорлардыгы үсеш дәрәҗәсен ничек билгеләгәннәр?

2. Ислам динен кабул иткәннән соң, сынлы сәнгатьнең нинди төрләре гамәлдә була?

3. 18 йөздә гамәли бизәлеш сәнгате төрләрен атагыз.

4. 19 йөз ахыры – 20 йөз башында иҗат итүче нинди сәнгать осталарын атый аласыз?

5. 20 йөзнең икенче яртысында нәкыш өлкәсендә нинди үзгәрешләр була?

**Биремнәр.**

1. Тексттан сингармонизмның ирен гармониясенә буйсынган һәм рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне табып языгыз.

2. Күтәрелмә һәм төшерелмә дифтонгларга өчәр мисал табып языгыз, алар белән яңа җөмләләр төзегез.

3. Текстта курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, алар белән сорау җөмләләр төзегез.

4. Текстны укыгыз, хронолик планын төзегез һәм иң әһәмиятле фикерләрне язып алыгыз.

5. Калын хәрефләр белән бирелгән сәнгать осталары турында тулырак мәгълүмат табып, әңгәмә корырга әзерләнегез.

**Тест.**

1. Нәкыш осталарын билгеләгез: а) Н.Фешин, П.Беньков; ә) В.Богатырев, С.Ахун; б) Ф.Таһиров, Г.Арсланов.
2. Графика осталарын билгеләгез: а) Н.Фешин, П.Беньков; ә) В.Богатырев, С.Ахун; б) Ф.Таһиров, Г.Арсланов.
3. Скульптура осталарын билгеләгез: а) Н.Фешин, П.Беньков; ә) В.Богатырев, С.Ахун; б) Ш.Мөхәммәтҗанов, Г. Арсланов.
4. П.Сперанский, М.Сүтүшев, Э.Гельмс, Ә.Тумашев – а) графика осталары; ә) гамәли һәм монументаль бизәлеш осталары; б) театр сәхнәсен бизәү осталары.
5. Татарстанда сынлы сәнгать үсешенә ..........................зур өлеш кертә. а) Казан сәнгать мәктәбе; ә) Казан сәнгать училищесы; б) Лениногорск музыка-сәнгать училищесы.
6. Татар халкының профессиональ милли сынлы сәнгате барлыкка килгән чор. а) 18 йөзнең икенче яртысы; ә) 18 йөз ахыры –19 йөз башы; б) 19 йөз ахыры – 20 йөз башы;

Сәнгать – халык күңелен, аның *мәгънәви тормышын* чагылдыра торган иҗади хезмәт. Шуңа күрә күпчелек очракта халык тарихын һәм хәзерге хәлен сәнгать, бигрәк тә сынлы сәнгать аркылы өйрәнәләр, танып беләләр. Мәсәлән, борынгы Римның Помпей *хәрабәләрендәге* һәм башка корылмаларындагы бизәкләрне, японнарның декоратив сәнгатен, кытай савыт-сабаларын, Иран келәмнәрен бөтен дөнья сокланып карый һәм бу милләтләр белән иң элек шулар аркылы таныша.

Татар халкының сынлы сәнгате бизәү һәм сырлаудан тора. Халык үзенең кием-салымын, йорт-җирен, көнкүреш *җиһазларын* гасырлар буе үзенә хас декоратив рәсемнәр белән бизәп килгән. Чабата үрү, чыпта тукудан башлап, катлаулы сарайлар салуга кадәр һәркайсында халыкның *иҗади зәвыгы* чагылган.

Сынлы сәнгать осталарын 1892 елда оешкан Казан сәнгать мәктәбендә әзерлиләр. Республикада халык сәнгате *мәсьәләләре* белән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Дәүләт музее шөгыльләнә.

Сынлы сәнгать *нәкыш,* скульптура, графика, коручылык һәм архитектура төрләренә бүленә. Татар дөньясында Исмәгыйль Гайнетдинов, монументаль нәкыш остасы Чыңгыз Әхмәров, *һәйкәлче* Садри Ахун (Тукай һәйкәле), рәссамнар Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Абрек Абзгильдин һ.б. – билгеле исемнәр (Ф.Валеевтан).

**Биремнәр.**

1. Тексттан [w] авазы булган сүзләрне һәм **ъ, ь** билгеләре кергән сүзләрне табып языгыз, орфографиясен аңлатыгыз.
2. Текстта курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.
3. Тексттагы *нәкыш, скульптура, графика, архитектура* кебек сәнгать терминнарының мәгънәләрен сүзлектән табып, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.
4. Японнарның декоратив сәнгате, кытай савыт-сабалары яки Иран келәмнәре турында татар телендә презентация ясагыз (7-8 слайд).
5. Текстта телгә алынган Исмәгыйль Гайнетдинов, Чыңгыз Әхмәровлар турында тулырак итеп сөйләргә әзерләнегез.

Натюрморт – голландиялеләр теленнән тәрҗемә иткәндә – “үле табигать” дигәнне аңлата. Аның төп нигезен *тормыш*-көнкүреш әйберләре, *өзеп* савытка яки өстәлгә куелган чәчәкләр, җиләк-җимеш, яшелчәләр һ.б. тәшкил итә. Бу жанр сынлы сәнгатьнең иң төп жанрларыннан санала.

Портрет ул – кеше яки берничә кеше сурәте. Әлеге жанр кешенең матурлыгын, *холкын*, характер үзенчәлекләрен сурәтләүгә юнәлдерелә. Портретта кешенең баш *өлеше* генә яки тулаем сурәтләнелә. Төсләр ярдәмендә кешенең изге яисә явыз ниятле булуын тасвирлап бирергә мөмкин.

Пейзаж ул – тере табигатьне сурәтләү дигән сүз. Элегрәк ул нинди дә булса күренешнең яки портретның арткы фоны гына булган. Пейзаж жанрын XVII гасырда Голландия рәссамнары тудыра. Илләрен Төньяк диңгезе суы басудан куркып, голландиялеләр дамбалар күтәрә башлыйлар, ә рәссамнар, табигатьнең матурлыгын сурәтләп калырга тырышып, диңгез ярларындагы *комны*, *көтүле болыннарны*, юлларны, елга янындагы җил тегермәннәрен рәсемгә *төшерергә* ашыгалар. Пейзаж жанрында табигатьнең теләсә-кайсы почмагын сурәтләп була, шулай ук кеше фантазиясе тудырган пейзажлар да була (Р. Султановадан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, аңа исем куегыз, эчтәлеге буенча биш сорау әзерләгез.
2. “Үле табигать” төшенчәсен ничек аңлыйсыз? Фикерегезне дәлилләгез. Бу жанрда иҗат ителгән күренекле әсәрләрне (авторлары белән) атагыз.
3. Текстта курсив белән бирелгән сүзләрне нинди үзенчәлек берләштерә? Алар арасында бер артык сүзне табыгыз.
4. Натюрморт, портрет яки пейзаж жанрында иҗат итүче берәр рәссам турында сөйләргә әзерләнегез.
5. Текстта телгә алынган жанрларның берсенә тулырак мәгълүмат әзерләп килегез.

**Татарстан Республикасының**
**дәүләт сынлы сәнгать музее**

Дәүләт сынлы сәнгать музееның тарихы Милли музейның 1895 елда ачылган сынлы сәнгать әсәрләре тупланмасыннан башлана. *Фонд археолог һәм туган якны өйрәнүче Андрей Лихачев, хәйрияче Ольга Александрова-Гейнс һәм рәссам Александр Мантель тапшырган әсәрләрдән туплана башлый. Алар музей коллекциясен Василий Тропинин, Иван Айвазовский, Василий Перов, Иван Шишкин, Константин Маковский, Илья Репин һәм Борис Кустодиев картиналары белән баеталар.*

1920 елда музейның 25 еллыгы уңаеннан аңа Татарстан Республикасының Үзәк музее статусы бирелә. Юбилей уңаеннан Дәүләт музее XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы рәссамнарының зур җыелмасын тапшыра.

*1950 еллардан башлап, Татарстан рәссамнарының сынлы сәнгать, графика, скульптура әсәрләрен туплау эше башлана. Шуларга нигезләнеп, музейда “Татарстанның һөнәри декоратив-гамәли сәнгате” дип исемләнгән даими эшләүче экспозиция ясала.* Сәнгать фонды туктаусыз үсә һәм 1958 елда РСФСР Мәдәният министрлыгы карары белән Милли музейның картиналар галереясе сынлы сәнгать музее итеп үзгәртелә. Ә 1967 елда хәзерге бинасына (Карл Маркс урамы, 64 йорт) күчерелә. Бу бина – 1906 елда Казан хәрби округы генералы А.Г. Сандецкий өчен салынган особняк. Александр Сандецкий биредә 1917 елгы революциягә кадәр яшәгән.

*2005 елда музейның филиалы – «Хәзинә» исемле Милли сынлы сәнгать галереясе ачыла. Әлеге галереядә импрессионист Николай Фешин, беренче профессиональ татар рәссамы Бакый Урманче һәм башкаларның иҗади әсәрләрен күрергә мөмкин.*

Хәзерге вакытта Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда 25 меңнән артык экспонат исәпләнә (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, әңгәмә корырга әзерләнегез.

2. Тексттан саннар кергән җөмләләрне табыгыз һәм (саннарны хәрефләр белән) күчереп языгыз.

3. Курсив белән бирелгән җөмләләрне, мәгънәсенә зыян килмәслек итеп, үзегезчә языгыз.

4. «Хәзинә» Милли сәнгать галереясе турында тулырак мәгълүмат туплап, презентацияле чыгыш әзерләп килегез.

5. Татарстан Республикасының сынлы сәнгать музеена сәяхәт кылыгыз, шул турыда инша язып килегез.

**Беренче тема буенча контроль сораулар.**

1. Татарстан Республикасының дәүләт сынлы сәнгать музеена кайчан нигез салына?

2. Татарстанның сынлы сәнгать музее нинди максат белән оештырыла?

3. Нәрсә ул пейзаж? Әлеге жанрда ижат ителгән берничә әсәрне (авторлары белән) атагыз.

4. Татарстан Республикасының дәүләт сынлы сәнгать музее Үзәк музей статусын ничәнче елда ала?

5. Татарстан рәссамнарының сынлы сәнгать, графика, скульптура әсәрләрен туплау эше кайчан башлана?

6. Нәрсә ул сәнгать?

7. Сынлы сәнгатьнең нинди төрләрен беләсез?

8. Татар халкының сынлы сәнгать осталарыннан кемнәрне беләсез?

9. Казан сәнгать мәктәбе кайчан оеша?

10. “Татарстанның һөнәри декоратив-гамәли сәнгате” исемле даими эшләп килгән экспозиция нәрсәләр нигезендә булдырыла?

**Тема буенча тәкъдим ителгән әдәбият**

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: ТР ФАнең Татар энцикл. ин-ты, 2002. 830 б.

Валиев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1974. 172 с.

Татар иле. http://tatarile.org/maglumat/tt

ИКЕНЧЕ ТЕМА

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БИЗӘЛЕШ СӘНГАТЕ

1. Болгар дәүләте һәм Алтын Урда дәверендә бизәлеш сәнгатенең үзенчәлекләре.
2. 16 – 18 йөзләрдә бизәлеш сәнгате.
3. 19 – 20 йөзләрдә бизәлеш сәнгате үзенчәлекләре.
4. Татарстанда бизәлеш сәнгате үсешенең хәзерге этабы.

## 1. **Болгар дәүләте һәм Алтын Урда дәверендә бизәлеш сәнгатенең үзенчәлекләре**

**Бизәлеш сәнгате**, нәфис сәнгатьнең бер тармагы, кеше яшәешенең көнкүреш мохитын формалаштыра торган иҗат төре. *Монументаль бизәлеш сәнгатен, гамәли бизәлеш сәнгатен* (халык кәсепчелеген кертеп), *бизәү сәнгатен* (бәйрәмнәр, күргәзмә һәм музей экспозицияләре, витриналар һ.б.ның сәнгатьле бизәлеше) берләштерә; *сәнгати сәнәгать* һәм дизайн белән бәйләнештә; авыл осталары, шәһәр һөнәрчеләре һәм профессиональ рәссамнар иҗатын **колачлый.** Бизәлеш сәнгате әсәрләре ансамбльнең бер өлеше буларак иҗат ителә, аларда сәнгатьнең берничә төре **синтезлана**. Татар халкында бизәлеш сәнгатенең тарихи тамырлары Евразиянең далалы һәм урман-далалы җирләрендә яшәгән *кабиләләр* мәдәниятенә, 4 – 5 йөзләр чигендәге һуннарның сәнгать **истәлекләренә** (корал һәм ат дирбиясе, зәркәнчелек эшләнмәләре үрнәкләре: алтын йөгертелгән әйберләр, кызыл h.б. төстәге пыяла кашлы бизәлмәләр), 6 – 7 йөзләрдәге *Көнчыгыш* һәм *Көнбатыш* төрки каганлыкларына, Бөек Болгарга, Хәзәр каганлыгына барып тоташа. Бизәлеш сәнгатенең урта гасырлардагы үсеше *әүвәлге* болгарлар (8 – 10 йөзләр), Идел буе Болгар дәүләте (10 йөз – 13 йөз башы), Алтын Урда (13 – 14 йөзләр), Алтын Урдадан соңгы татар ханлыклары (15 – 16 йөз уртасы) *дәверләрен*ә бүлеп өйрәнелә.

Болгар дәүләте һәм Алтын Урда **дәверләре** бизәлеш сәнгате стиле үзенчәлекләре Казан һ.б. татар ханлыклары сәнгатендә дәвамлы рәвештә үсә. Шәһәр *дөньяви* мәдәниятенең һәм *Шәрыкшщрек бароккосы* дип аталган стильне чагылдырган шәһәр һөнәрчелеге традицияләре хакында монументаль архитектура бизәгенең сакланып калган фрагментларына (уеп бизәкләнгән таш детальләр, алебастр плитәләр), уеп язылган кабер ташлары һәм Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган Казан бүреге, алтын каптырмалар кебек зәргәрчелек сәнгатенең *уникаль* үрнәкләренә карап фикер йөртергә мөмкин. 16 йөзнең икенче яртысыннан, Казан һәм Әстерхан ханлыклары яулап алынып, Рус дәүләтенә кушылганнан соң, татар бизәлеш сәнгате **фәкать** халык иҗаты формаларында гына яшәп кала, чөнки шәһәрләрдәге *һөнәрчелек* үзәкләре таркала, бизәлеш сәнгате әсәрләрен кулланучы һәм үстерүче югары катлау юкка чыга. Бизәлеш сәнгатенең монументаль архитектура белән бәйләнгән төрләре, нәфис керәч (татарларның чүлмәк балчыгы чыга торган урыннардан куылуы сәбәпле), кыздырып металл эшкәртү (рәсми рәвештә тыела) һәм, гомумән, югары *зәвыклы* элитар эшләнмәләр җитештерү кебек кәсепләр үсеше туктала. Бизәлеш сәнгатенең зур үсеш алган традицияләре шәһәр сыман борынгы татар үзәкләрендә (Арча, Саба) һәм алар тирәсендәге авылларда яшәп кала (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, сәнгать өлкәсенә караган терминнарны табыгыз, аларның бишесенең билгеләмәләрен сүзлектән язып алыгыз һәм истә калдырыгыз.
2. Курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз һәм сүзлек диктантына әзерләнегез.
3. Калын хәрефле сүзләрнең синонимнарын табыгыз.
4. Текст буенча төркемдәшләрегезгә биш сорау әзерләп, әңгәмә корырга әзерләнегез.
5. Тексттан тиңдәш кисәкле иң озын җөмләне табып, мәгънәсенә зыян китермәслек итеп, үзегезчә үзгәртеп языгыз.

**Тест.**

*1. Көнкүреш* – а) кушма сүз; ә) ясагыч кушымчалы сүз; б) тамыр сүз.

*2. Урман-далалы* – а) парлы исем; ә) тезмә сыйфат; б) парлы сыйфат.

*3. Эшләнмәләр* – а) исем; ә) фигыль; б) сыйфат.

*4. Сәнгать* сүзендә а) 7 хәреф, 7 аваз; ә) 6 аваз, 7 хәреф; б) 6 хәреф, 7 аваз.

*5. Яшәеш* сүзендә а) 7 аваз, 5 хәреф; ә) 6 аваз, 5 хәреф; б) 5 аваз, 5 хәреф.

**2. 16-18 йөзләрдә бизәлеш сәнгате**

16 йөз урталарында Татарстан җирләренә Рус бизәлеш сәнгате үтеп керә; ташка һәм агачка архитектура бизәге ую, дивар нәкыше, әвәләп һәм чынаяк кирпечтән ясалган бизәк, чиркәү әйберләрен укалап чигү, көнкүрештә кулланылган керәч әйберләр (савыт-саба, кикрикле кош башы рәвешендәге борынлы комганнар һ.б.), металлны нәфис эшкәртү (көмеш һәм бакыр кою, *чәкәнләү, уемлау*) һәм зәркән сәнгате (**каралту, җепкыр, финифть**) үсеш ала. 18 йөз башыннан бизәлеш сәнгате *гомумрус* мәдәниятенең тарихи стильләр (барокко, классицизм, ампир, модерн, экликтика) һәм җирле провинциаль үзенчәлекләр этапларын кичерә. Ташка уелган рельефлы һәм алебастрдан әвәләп ясалган бизәк, күпертмә бизәк, нәкыш, бина фасадларындагы агачка уелган бизәкләр, иконостасларны алтынлау, тәрәзә һәм ялтыравык йөгертелгән керәчтән мич тышлыклары һ.б. монументаль бизәлеш төрләре – моның ачык мисалы. Гамәли бизәлеш төрләреннән нәфис савыт-саба, мичләр һәм идән тышлаулары ясауда керәч һөнәрчелеге (Кокшан керәч заводы), «кустар» нәфис кәсепчелек (тимерчеләр, зәркәнчеләр, чүлмәкчеләр), шулай ук рус халык сәнгатенең тегү, чигү, туку, агачны уеп кисү һәм бизәкләү кебек төрләре үсеш ала.

Татар бизәлеш сәнгате тарихында 18 йөз урталарыннан 19 йөз урталарына кадәрге чор чәчәк ату дәвере буларак билгеләнә. Әлеге чорда бизәлеш сәнгате феодализм дәвере казанышларын саклаган авыл шартларында үскән халык мәдәнияте һәм гореф-гадәтләрнең үзара йогынты ясау шартларында үсә, бу исә классик формаларның барлыкка килүе өчен җирлек бирә. Бизәлеш сәнгате

әсәрләре матди-нәфис кәсепчелекнең барлык тармакларында да иҗат итеЛә, нәтиҗәдә мәдәнияттә *милләткүләм* традицияләр формалашуга этәргеч туа. 18 йөз урталарыннан 19 йөз урталарына кадәрге чорда милли татар киемнәре, татар өйләренең эчке һәм тышкы бизәлеше, бизәлеш сәнгате әсәрләренең *милли бизәкләр* һәм төсләр кануннары формалаша. Каюлы күн, зәргәрчелек, укалап һәм элмәкләп чигү, туку, хаттатчылык кебек сәнгать төрләрендә татар осталарына хас ысуллар үсеш ала. Бизәлеш сәнгатенең классик формалары Идел буе һәм Урал төбәге татарларының шәһәр мәдәнияте нигезендә барлыкка килә. Казан һәм Казан артының һөнәрчелек алга киткән, *нәфис кәсепчелек ширкәтләре* булган борынгы авыллары бизәлеш сәнгате үзәкләренә әверелә. Бу исә татар халкының барлык *этник төркемнәренең* (Идел буе, Урал төбәге һәм Көнбатыш Себер), шул исәптән башкортларның һәм беркадәр күләмдә казакъларның ихтыяҗларына җавап бирүче *эшләнмәләрне* күпләп җитештерү мөмкинлеген ача. 18 йөзнең икенче яртысыннан татарлар яшәгән урыннарда шәһәр нәфис һөнәрчелеге яңарыш кичерә (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, сезнең карашка иң әһәмиятле булган биш фикерне җөмләсе белән язып алыгыз һәм сораулар куегыз.
2. Зәркән сәнгатенә караган *каралту, җепкыр, финифть* кебек терминнарның мәгънәләрен аңлатып бирегез.
3. Изафә бәйләнешендәге исемнәргә 10 мисал язып алыгыз, бишесе белән җөмләләр төзегез.
4. Тексттан ялгызлык атамаларын язып алыгыз, шуларның берсе турында 7-8 җөмләдән торган мәгълүмат әзерләгез.
5. Текст буенча кроссворд төзегез.
6. Курсив белән бирелгән сүзләрне русчага тәрҗемә итегез.

## 3. 19-20 йөзләрдә бизәлеш сәнгате үзенчәлекләре

19 йөз урталарыннан бизәлеш сәнгатенә каюлы күн һәм **бизәкле** киез итекләре, ирләр һәм хатын-кызлар өчен укалап чиккән баш һәм аяк киемнәре, киез һәм тукылган келәмнәр җитештерү керә. Б.с.нең **традицион** төрләре татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә (Идел буенда һәм Урал алды төбәгендә, Көнбатыш Себердә һәм Кырымда) киң тарала. Зәркән бизәлмәләр, чигелгән бизәкләр, тукыма әйберләр, бакырдан һәм җиздән ясалган эшләнмәләр, шәмаилләр һ.б. ***гаммәви*** *һөнәрчелек* продукциясе рәвешендә җитештерелә. Әлеге эшләнмәләргә **күпмилләтле** төбәктә һәм ерак җирләрдә – Казахстан, Урта Азия, Себердә *ихтыяҗ* зур булганлыктан, аларны җитештерү күп кенә авылларда халык өчен **әһәмиятле** кәсепчелеккә әверелә. 19 йөзнең икенче яртысыннан 20 йөз башларына кадәр ***гомуммилли*** бизәлеш сәнгате әйберләренең күпләп җитештерелүе бердәй кабатланган формаларны барлыкка китерә. Бизәлеш сәнгатенең сәнгати-эстетик системасы формалашуда ислам сәнгате принциплары, рус һәм Европа сәнгатенең классицизм, барокко, ампир стильләре **мөһим** роль уйный (таш һәм агач биналар бизәүдә, зәргәрчелек сәнгатендә, өс киеме тегүдә, келәм тукуда һ.б.).

19 йөз ахыры – 20 йөз башы татар бизәлеш сәнгатенә Европа модаларының үтеп керүе бизәлеш сәнгатенең күп кенә төрләре, башлыча, традицион интерьер һәм өс киемнәренең искергән формалары юкка чыгуга сәбәп була. Шул ук вакытта рәссамның индивидуаль иҗатына нигезләнгән профессиональ сәнгатьнең мәдәнияттә мөстәкыйль бер төр булып формалашуы өчен алшартлар туа.

1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында кустар һөнәрчелекнең кооперативларга берләшүе нәтиҗәсендә, Татарстанда нәфис һөнәрчелек һәм кәсепчелекнең күп кенә төрләре юкка чыга. Иҗтимагый биналарның интерьерларын бизәү проектлары, гаммәви агитация кебек төрләре өстенлек ала. Шулай ук бизәлеш сәнгатенең кайбер төрләре (ташка, бетонга, агачка уеп бизәк ясау, алебастрдан әвәләп бизәк ясау) иҗтимагый биналар һәм торак йортлар бизәлешендә кулланыла. Аларда рус классик архитектурасы принциплары татар милли архитектурасындагы, татар йортларындагы бизәлеш формалары

белән бергә яраштырыла. Интерьерлардагы рельеф гипс бизәкләр, киндердә башкарылган сынлы паннолар, фреска һәм темпера нәкышләре, **зиннәтле** җиһазлар һ.б. кулланыла (архитекторлар И. Гайнетдинов, Р. Мортазин, И. Вәлиев, рәссамнар С. Ахун, Ч. Әхмәров, П. Сперанский, В. Ламмерт һ.б. иҗаты).

1950 еллар башыннан бизәлеш сәнгате үсә башлый: бу интерьерларны проектлауда, **агитацион** паннолар, күргәзмә экспозицияләре иҗат итүдә, бәйрәмнәрне бизәүдә **эшләүче** рәссамнәр иҗатында күзәтелә (А. Кашаев, Д. Булат, А. Крылов, И. Игъламов, Н. Байбурин, П. Тужилкин һ.б.).

1960 еллардан бизәлеш сәнгате яңа сулыш ала: шәһәрләрдә төзелешнең үсүе бизәлеш сәнгатенең монументаль бизәлеш төренә, нәфис эшләнмәләргә ихтыяҗ арта. Россия югары уку йортларын тәмамлаган **яшь** буын рәссамнар тырышлыгы белән бизәлеш сәнгате өлкәсендә профессиональ иҗат барлыкка килә (Н. Артамонов, С. Бубеннов, Р. Килдебәков, М. Килдебәкова, Е. Киселёва, В. Ковалевский, С. Кузьминых, М. Шәйдуллин, С. Шәкүрова, Б. Шубин, А. Спориус, А. Сысоев, В. Федоров һ.б.).

1970 еллар ахыры – 80 еллар уртасы – бизәлеш сәнгатенең күтәрелеш дәвере. Бу чорда аның дивар мозаикасы, витраж, батик, гобелен, кием модельләү, керәч, фарфор һәм фаянс җитештерү кебек **яңа** төрләре барлыкка килә. Рәссамнарның зур коллективлары Казанда гына түгел, Яр Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә һ.б. шәһәрләрдә оеша. 1983 елда беренче тапкыр бизәлеш сәнгатенең республика күргәзмәсе үткәрелә, анда 81 авторның 276 эше күрсәтелә (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Биремнәр.**

1. Икенче абзацтагы җөмләләрне берләштереп, төп мәгънәгә зыян килмәслек итеп, үзгәртеп языгыз.
2. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне нинди уртаклык берләштерә? Алар арасында бер артык сүзне күрсәтегез. Фикерегезне дәлилләгез.
3. Тексттан сезнең карашка иң әһәмиятле булган 7 җөмләне күчереп языгыз, аларга сораулар куегыз.

4. *Фреска* һәм *темпера* нәкышләре турында тулырак мәгълүмат әзерләгез.

5. Бизәлеш сәнгатенең дивар мозаикасы, витраж, батик, гобелен, кием модельләү, керәч, фарфор һәм фаянс җитештерү кебек төрләренең берсе турында презентацияле чыгышка әзерләнегез.

**Тест.**

1. *Һөнәрчелек продукциясе* сүзенең русчага тәрҗемәсе – а) профессиональная продукция; ә) ремесленная продукция; б) кустарная продукция.
2. Гаммәви сүзенең рус теленә тәрҗемәсе а) массовая; ә) общая; б) практическая.
3. *Алшарт* – а) саф кушма сүз; ә) тезмә сүз; б) тамыр сүз.
4. Бизәлеш сәнгатенең күтәрелеш дәвере – а) 1950 еллар ахыры – 60 еллар уртасы; ә) 1960 еллар ахыры – 70 еллар башы; б) 1970 еллар ахыры – 80 еллар уртасы.
5. Европа сәнгатенең классицизм, барокко, ампир стильләре нинди сәнгатьтә күзәтелә? а) таш һәм агач биналар бизәүдә; ә) каюлы күн һәм бизәкле киез итекләр бизәлешендә; б) бакырдан һәм җиздән ясалган эшләнмәләрдә.

**4. Татарстанда бизәлеш сәнгате үсешенең хәзерге этабы**

ТРда бизәлеш сәнгате үсешенең хәзерге этабы милли сәнгать, татар һәм ислам *мәдәнияте* традицияләрен үзләштерү аша милли формаларга омтылу, ш.у. дизайн һәм төзелеш өлкәсендә авангард тенденцияләрен эзләү белән аерылып тора. Бизәлеш сәнгате өлкәсендә профессиональ рәссамнар белән *берррәттән*, традицион һөнәрләрне үстерүче, халык осталары, нәфис кәсепчелектә махсус һөнәри-техник белемле осталар һәм үзешчән рәссамнар да эшли. Алар милли сувенирлар, бүләкләр, күргәзмә әсәрләре җитештерүче төрле ширкәтләргә берләшәләр. Авыл өйләре бизәлешендә агачка уелган бизәк, *күптөрле* төсләр белән буяу, тукуның иң гади төрләре, чигү, зәркән бизәлмәләренең кайбер төрләре көнкүрештә яшәп килә. Каюлы аяк киеме, керәчтән ясалган курчаклар җитештерү, рус һәм татар традицияләренә нигезләнгән бизәкләп туку халык нәфис

кәсепчелеге формаларында үсешен дәвам итә. Бизәлеш сәнгатенең күн эшкәртү (күн каю һ.б.), уникаль нәфис текстиль (батик, гобелен, чигү, алтын җепләр белән тегү), зәргәрчелек сәнгате, металлны нәфис эшкәртү, өс киеме сәнгате, агач ую, керәч һ.б. төрләре, монументаль бизәлеш төрләре буларак, дивар рәсемнәре, мозаика, гипсны уеп бизәкләү, тукыма паннолар һ.б актив рәвештә үсә.

20 йөзнең соңгы *унъеллыкларында* дизайн өлкәсендәге эшчәнлек киңәя һәм яңа эчтәлек белән тулылана. Дизайнның классик төрләреннән кала, архитектура, гамәли һәм хәтта сынлы сәнгать өлкәсенә үтеп кергән арт-дизайн, график-дизайн кебек яңа төрләр барлыкка килә. Казан архитектура-төзелеш университетында 1991 елда нигез салынган дизайн факультеты һәм архитектура мохите дизайны кафедрасы архитектура дизайны өлкәсендә белем бирү һәм фәнни проектлар эшләү үзәгенә әверелә. Кафедра Россия югары уку йортлары арасында архитектура *мохите* дизайны өлкәсендә әйдәп баручыларның берсенә әйләнә; биредә дәреслекләр, белешмәләр һәм С.М. Михайловның «Дизайн тарихы» дип аталган икетомлыгы дөнья күрә. Әлеге хезмәте өчен С.М. Михайлов Халыкара дизайнчылар берлеге дипломына һәм РФнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә (2003) лаек була. ТР Дизайнчылар берлеге канаты астында Казанда РФ Дизайнчылар берлегенең IV Ассамблеясе (съезды) һәм беренче *бөтенроссия* «Дизайн дөньясы» фестивале үткәрелә. 1996 елда Казанның Баш архитектура-планлаштыру идарәсе каршында Шәһәр дизайны идарәсе оештырыла. Сәнгать фондында 2001 елдан рәсми рәвештә баш дизайнчы *вазифасы* булдырыла. 2004 елда биредә интерьерлар бизәү, ландшафтлы дизайн, кече архитектур формалар, ТР шәһәрләрен бәйрәмчә бизәү белән шөгыльләнүче дизайн һәм сәнгатьчә проектлау бүлеге оештырыла. Дизайнчылар Р. Гыймранов (җитәкче), В. Нестеренко, Р. Абаев, А. Лопаткин һ.б. дан торган «ДД» иҗат төркеме Казандагы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгенең (2003) сәнгатьчә бизәлешен башкаралар. Дизайнның сәнгать юнәлеше өлкәсендә белем бирү Казан сәнгать училищесында (2001 елдан ) алып барыла; 2003 елда Казан технология университетында (Җиңел сәнәгать институтында) дизайн һәм *конструкцияләү* факультетына нигез

салына. 1998 елдан «Дизайн и новая архитектура» журналы чыга башлый (Ю. Нигъмәтуллинадан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.

2. Тексттан парлы, кушма һәм тезмә сүзләрне язып алыгыз. Кушма сүзләрнең һәр өч төренә бишәр мисал уйлап языгыз.

3. Курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, сүзлек диктантына әзерләнегез.

4. «Дизайн и новая архитектура» журналыннан сезнең карашка кызыклы булган бер мәкаләне сайлап алып, татарчага тәрҗемә итегез.

5. Арт-дизайн яки график-дизайн турында тулырак мәгълүмат туплап, чыгыш ясарга әзерләнегез

**Тест.**

1. «Дизайн тарихы» дип аталган хезмәтнең авторы кем?
*а) Р. Гыйммранов; ә) С.М. Михайлов; б) В. Нестеренко.*

2. Казан архитектура-төзелеш университетының дизайн факультетына ничәнче елда нигез салына? *а)1991; ә) 2001; б)1993.*

3. Беренче бөтенроссия «Дизайн дөньясы» фестивале үткәрелгән ел. *А) 1991; ә) 1994; б) 1996.*

4. Казанның Баш архитектура-планлаштыру идарәсе каршында Шәһәр дизайны идарәсе оештырылган ел.
*а) 1991; ә) 1994; б) 1996.*

5. Рәссамнар берлегенең Сәнгать фондында баш дизайнчы вазифасы рәсми рәвештә ничәнче елда булдырыла? *а) 1991; ә) 2001; б) 1993.*

**Сораулар.**

1. 90 нчы еллар ахырында дизайн сәнгатенең нинди яңа төрләре барлыкка килә?

2. С.М. Михайлов «Дизайн тарихы» дип аталган икетомлык хезмәте өчен нинди бүләккә лаек була?

3. «Дизайн и новая архитектура» журналы ничәнче елда чыга башлый?

4. Дизайнчылардан кемнәрне атый аласыз?

**Дизайн** – форманы максатка ярашлы итеп төзүдә кулланылган иҗади алым, шулай ук сәнәгать эшләнмәләрен**, йорт** җиһазларын, эш коралларын, машиналарны проектлауда, матди мохитне һәм хезмәт процессларын **оештыруда** профессиональ эшчәнлек өлкәсе. Дизайн кул эшен машина белән башкаруга күчү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Профессиональ эшчәнлекнең **яңа** төре булачак эшләнмәнең проектын кәгазьдә ясау яки моделен төзүгә кайтып кала. «Дизайн» атамасы 1826 елда, Америкадагы Нәфис сәнгать академиясе Милли дизайн академиясе итеп үзгәртеп корылгач, кулланыла **башлый**. Дизайн иҗатында төп принцип: функция – конструкция – эстетик форма (сыйфат). Дизайн үсешендә ике **юнәлеш** барлыкка килә: *индустриаль* дизайн һәм *концептуаль* (программалы) дизайн; җитештерү төрләре буенча ул массачыл һәм уникаль дизайнга бүленә. Төп төрләре: сәнәгать (эшләнмәләр) дизайны (механизмнар, транспорт, көнкүреш приборлары, савыт-саба, **кием-**салым һ.б.), мохит дизайны (торак һәм җәмәгать биналарының интерьерлары, шәһәр *мәйданнары* һ.б.), график дизайн (сәнәгать графикасы, газета-журнал графикасы, реклама полиграфиясе һ.б.), реклама дизайны һ.б. (С. Михайловтан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, басымның соңгы иҗеккә төшмәгән очракларына мисаллар табыгыз, фикерегезне дәлилләгез.
2. Калын хәрефле сүзләргә игътибар итегез. Аларны нинди үзенчәлек берләштерә? Фикерегезне дәлилләгез һәм әлеге җөмләләрне күчереп языгыз.
3. Текстта сезнең карашка иң әһәмиятле булган 5 җөмләне сайлап алыгыз, алардан сорау җөмләләр төзегез.
4. *Индустриаль* һәм *концептуаль* (программалы) дизайн турында тулырак мәгълүмат туплап, текстны тулыландырыгыз.
5. Дизайнның төп төрләрен атагыз, берсе турында татарча презентация белән чыгыш әзерләгез.
6. “Дизайнер ул – матурлык тудыручы” темасына инша язып килегез.

**Тема буенча контроль сораулар.**

1. Бизәлеш сәнгатенә билгеләмә бирегез һәм аның төрләрен атагыз.

2. Татар б.с.нең традицион төрләре нинди төбәкләрдә киң таралыш алган?

3. Болгар дәүләте дәверендә бизәлеш сәнгатенең үзенчәлекләрен санап чыгыгыз.

4. Алтын Урда чорындагы бизәлеш сәнгатенең үзенчәлекләрен атагыз.

5. Бизәлеш сәнгатенең классик формалары нәрсәләр нигезендә барлыкка килә?

6. Классик төрләрдән тыш, архитектура, гамәли һәм сынлы сәнгать өлкәсендә дизайнның нинди яңа төрләр барлыкка килә?

7. Татарстанда бизәлеш сәнгате үсешенең хәзерге этабының төп үзенчәлекләрен атагыз.

8. Дизайн иҗатының төп принципларын атагыз.

9. Дизайн атамасы кайчан кулланыла башлый?

10. Җитештерү төрләре буенча дизайнның нинди төрләрен беләсез?

**Тема буенча тәкъдим ителә торган әдәбият**

Воронов Н. Развитие термина «дизайн» и его практики // Декоративное искусство. 2003. 238 с.

Валеева Д.К. Искусство Татарстана (20 век). К., 1999. 288 с.

Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. Казань, 1995. 146 с.

Глазычев В. Дизайн как он есть. Изд.2-е, доп. М.: Издательство «Европа», 2006. 320 с.

ӨЧЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ СӘНГАТЬ ТӨРЛӘРЕ

1. Татар халкының чигү сәнгате.
2. Татар халкының күн сәнгате.
3. Татар халкының керәч сәнгате.
4. Татар халкының гобелен сәнгате.

### 1. Татар халкының чигү сәнгате

Татар халкының чигү сәнгате бик борынгыдан килгән. Аның традицияләре Идел буе болгарларына һәм Казан ханлыгы чорына барып тоташа. Археология материалларына караганда, мәсәлән, **ефәк** җепләр белән алтынлап һәм көмешләп чигү ысулы Болгар халкы арасында киң таралган булган.

XIX йөздә фабрикаларда җитештерелгән бизәкле тукымалар киң таралу сәбәпле, халыкта чигү сәнгате беркадәр сүрелә төшә, әмма аның кайбер төрләре әле булса яшәүләрен дәвам итәләр.

Безнең бабаларыбыз шартлы билгеләрдән, символлардан гади бизәкләр ясаганнар. Горизонталь, туры сызыклар белән җир өслеген, дулкын белән суны билгеләгәннәр. Түгәрәк, квадрат, ромб фигуралары белән кояш, ай сурәтләнгән. Күп төрле **бизәкләр** белән чигелгән әйберләр саклау бөтиләре булып саналган.

Нәкышләрдә чагылган роза чәчәге матурлык һәм мәхәббәт билгесе булган. Артыш, гөлҗимеш, миләш – бәхет китерүче **үсемлекләр**. Бүгенге көндә дә аларның чәчәк-яфракларын, ботакларын талисман итеп кулланалар. Күптаҗлы булгангадыр инде, кашкарыйлар озын гомер символы итеп санала. Язның беренче чәчәкләреннән булган һәм бизәкләрдә еш кулланыла торган лалә чәчәге үзгәреш, **яңарышны** аңлата. Урталай бүленгән гранат җимеше сурәтләү уңдырышлылыкны, байлыкны белдерә. Идел буе болгарларыннан ук килә торган,

башка халыкларда да популяр булган чәчәк бәйләме темасы яшәү чыганагы символы булып тора. Кошлар яисә кош каурые мотивлары, сары төс белән беррәттән, барлык төрки халыкларда да **кояш**, яктылык символы булып кабул ителгән. Ак төс сафлык, пакьлек билгесе дип санала. Күргәнебезчә, чигү җирлегенең төсе дә ниндидер мәгънә белдерә, бизәкне бербөтен итеп, җыеп, тулыландырып тора (“Белем.ру”сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне иҗекләргә бүлегез, иҗек төрләрен билгеләгез. Бу сүзләр белән яңа җөмләләр языгыз.
2. Тексттан калын **к, г** авазы кергән сүзләрне язып алыгыз, аларның язылышын истә калдырыгыз. Әлеге авазлар кулланылган сүзләрне мәкаль яки әйтемнәрдән табыгыз, һәр ике авазга мисал итеп, бишәр мәкаль язып килегез.
3. Текстның эчтәлеге белән танышыгыз һәм текст буенча кроссворд төзегез.
4. Ренат Сәфәровның “Татарский орнамент глазами дизайнера” китабы белән танышыгыз, китап турында фикерләрегез белән уртаклашыгыз.
5. Түбәндә текст эчтәлеге белән туры килмәгән җөмләләр бирелгән, аларны дөресләп, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз: *Лалә чәчәге озын гомер символы булып санала. Кошлар яисә кош каурые мотивлары, сары төс белән беррәттән, барлык төрки халыкларда да тынычлык символы булып кабул ителгән. Артыш, гөлҗимеш, миләш – мәхәббәт китерүче үсемлекләр. Күп кенә халыкларда популяр булган чәчәк бәйләме темасы бердәмлек символы булып тора. Нәкышләрдә чагылган ярты анар җимеше яңарышны белдерә. Гөлчәчәк – яңарышны аңлатса, кашкарый матурлык һәм мәхәббәт билгесе булган.*

**2. Татар халкында күн сәнгате**

Болгар илендә ...................... эшкәртү алымнары борын-борыннан булган. Югары сыйфатлы сафьяннан, юфтьтән эшләнгән күн читекләрне, туфлиләрне .................. кына түгел, бәлки бүтән төбәк халкы да яратып кигән. *Аяк бизәкләп шактый булган техникасы киеме җитештерү катлаулы эшләнгән.* Осталар **берьюлы** берничә пар аяк киеме килеп чыгардай калдыксыз эшләү юлын тапканнар. Аяк киеме кисүче төрле төскә буялган юеш күнне бер өем итеп куйган һәм берничә читек өчен берьюлы ................ кискән. Аннан соң, күн катламнар арасында кайбер элементларны алыштыргач, төрле төстәге бизәкләр барлыкка килгән. Бизәкнең контуры булып торган махсус декоратив җөй ярдәмендә әлеге элементлар ............... .............. белән төзелгән һәм беркетелеп куелган.

*Үзенчәлекле мәгънәсе саклау-магия аяк бизәкләренә киеменең бирелгән элек-электән кешене.* Бизәкләр нигезендә – үсемлек һәм җәнлек мотивлары. Алар арасында **болытсыман, лотоссыман** сурәтләр, пальметта, лалә чәчәге киң таралган. Читек элементлары батика бизәкләрдән мөгез, песи башы, йөрәк формасындагы ................ белән аерылып тора. *Суны өске мотивы өлешендәге дулкын читекнең символлаштыра.* Төсле фон ярдәмендә шактый эре зур һәм йомык формалы элементлар **бербөтен** һәм үзенчәлекле бизәк композициясен тәшкил итә (“Белем.ру”сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Тексттан төшеп калган сүз һәм сүзтезмәләрне тиешле урыннарга куеп, җөмләләрне күчереп языгыз: *бизәкне, җирле халык, мозаика техникасы, сурәтләр, күн-тирене.*

2. Курсив белән бирелгән сүзләрне тиешле тәртиптә урнаштырыгыз һәм алардан сорау җөмләләр төзегез.

3. Текстта калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең язылышына игътибар итегез, татар телендә шундый тел берәмлекләренең башка мисалларын табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

4. Тексттан сәнгать өлкәсенә караган 3 терминны язып алыгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз.

5. Текст буенча диктант язарга әзерләнегез.

## 3. Татар халкының керәч сәнгате

Керәч сәнгате– яндырылган махсус кушылмалы балчыктан төрле нәфис эшләнмәләр ясау. Ул гамәли-бизәлеш һәм монументаль-бизәлеш сәнгате өлкәсенә карый. Керәч сәнгате чүлмәк ясау, терракота, майолика, мозаика, фаянс, фарфор савыт-саба, вазалар, сыннар, дивар паннолары, архитектур чынаяк кирпечләр, уенчыклар, бизәкләр һ.б. әйберләр иҗат итү өчен файдаланыла. Татарларда керәч сәнгате «керәч» исеме белән мәгълүм һәм нәфис һөнәрчелектә традицион төрләрнең берсе.

Татарстан территориясендә керәч эшләнмәләрнең иң әүвәлге табылдыклары неолит дәверенә карый. алар арасында зигзаглар, ромблар, өчпочмаклар, тараксыман штамп, үрелгән шнур рәвешендәге һәм иң гади геометрик бизәкләр белән сырланган чүлмәк савытларны мисалга китерергә мөмкин. Бакыр һәм бронза гасырларда савыт формалары тагын да төрлеләнә бара, орнамент мотивлары катлаулана өслекләр шомартыла, ялтыратыла.

Керәч сәнгатенең җитлеккән вакыты X – XIII гасырларга, ягъни форма бирү, бизәк төшерү культурасының югары дәрәҗәгә ирешкән чорына карый. Бер яки ике саплы амфора рәвешендәге кувшиннар, коштабаклар, чүлмәкләр, комганнар һ.б.ш. савыт-сабалар, шәмдәлләр, кара савытлары, уенчыклар кул белән әвәләп тә, чүлмәк ясау тәгәрмәче белән дә эшләнә. Алар үлчәвенә туры килә торган пропорцияләре, буяуларның ачыклыгы (якты сарыдан, томанлы сорыдан кызыл һәм куе кызгылт көрән төскә кадәр) һәм бизәкле (үрмәләр, үсемлек сабаклары, каймалар, каннелюрлар, штрихланган өчпочмаклар, «йөгерек дулкын» мотивлары, интеграль спираль һ.б.) композицияләре белән аерылып торалар. Эшләнмәне ангоб (ак, кызыл, соры балчык), үтә күренмәле чүлмәк лагы белән каплау (сыек яшелдән кара төскә кадәр) һәм буйлы сызыклар рәвешендә шомарту алымы киң тарала. Пыяласыман ялтыравык йөгертелгән керәч сәнгате еш кына контррельефлы бизәк белән яраша. Болгар керәч сәнгатенең формалары да үзенчәлекле – сылап ясалган киек-җәнлек гәүдәләре (алгы өлеше) һәм башлары (үгез, ат, сарык, эт, поши, үрдәк, әтәч һ.б.) эшләнмәләрнең түгәрәк өлешен тәшкил иткән һәм әйбернең сапларын, борыннарын бизәгән. Кайбер

очракта табыну һәм саклау мәгънәсенә ия булган җәнлек һәм кош сурәтләре шартлы рәвештә ярымтүгәрәк чыгынты формасы белән алмаштырылган (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, эчтәлеге буенча төркемдәшләрегезгә 5 сорау әзерләгез.
2. Тексттан керәч сәнгатенең төп үзенчәлекләрен яктырткан биш фикерне әйтеп бирегез.
3. Тексттагы җөмләләрнең күбесен нинди уртаклык берләштерә? Бу үзенчәлеккә ия булмаган җөмләләрне язып алыгыз.
4. Тексттан сәнгать өлкәсенә караган терминнарны табыгыз һәм “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ннән мәгънәләрен язып алыгыз, икесе турында тулырак мәгълүмат әзерләгез.
5. Түбәндәге фразеологизмнарның нинди мәгънәләрдә кулланылуын ачыклагыз: *бизәкләп-сырлап тормау, чүлмәкчедән күрмәкче, агачтан сандугач кына ясамау.* Үзегезгә ошаган теләсә-нинди ике фразеологизмга рәсем ясап килегез.

**Тест.**

1. Татарстан территориясендә керәч эшләнмәләрнең иң әүвәлге табылдыклары кайсы чорга карый? *а) мезолит ә) неолит; б) палеолит.*
2. *Бизәк төшерү культурасының югары дәрәҗәгә ирешкән чорын билгеләгез: а) IV-VII гасырлар; ә) X-XIII гасырлар; б) VIII-IX гасырлар.*
3. Керәч сәнгатендә нинди төстәге буяу кулланылмаган?
а) *ачык сары; ә) ачык зәңгәр; б) куе кызгылт.*
4. Керәч эшләнмәләрен ясауда кулланылган алымны билгеләгез: *а) аркылы сызыклар рәвешендә шомарту; ә) ялтыравык йөгертү; б) ак, кызыл, соры балчык белән каплау.*
5. Дөрес булмаган фикерне билгеләгез. *а) Керәч сәнгате – яндырылган махсус кушылмалы балчыктан төрле нәфис эшләнмәләр ясау; ә) Болгар керәч сәнгатендә чокып ясалган киек-җәнлек гәүдәләре һәм башлары*

*эшләнмәләрнең түгәрәк өлешен тәшкил иткән; б) Керәч сәнгатендә җәнлек һәм кош сурәтләре табыну һәм саклау мәгънәсенә ия булган;*

**4. Татар халкының гобелен сәнгате**

**Гобелен** – бизәлеш максатларында кулдан тукылган югары *сәнгати кыйммәткә* ия тукыма; тукылган рәсемнәр, дивар келәмнәре һ.б. Татарстанда гобелен сәнгатенә М.С. Килдебәкова нигез сала. 1964 елда ул республикада беренче булып, келәм туку ысулы белән «Музыкант» дип исемләнгән сюжетлы гобелен эшли. 1974-90 да М.С. Килдебәкова республика Сәнгать фонды каршында А.Н. Егоров, Г.Н. Маликова, Г.Шәрипова катнашында оешкан *һөнәр остаханәсен* җитәкли. Эшчәнлекләрен алар иҗат бригадасына берләшеп башлыйлар, һәм беренче **киң** күләмле эшләре Казан көнкүреш йортының үзәк демонстрацияләү залы диварында келәм ысулы белән тукылган «Татарстан» гобелены була. Остаханә рәссамнары иҗатында ике юнәлеш – орнамент белән бизәлешле гобелен һәм сюжетлы-тематик юнәлешләр билгеләнә.

1970 еллар ахыры – 1980 еллар – Татарстанда гобелен сәнгатенең чәчәк ату чоры. Аңа Россия сәнгать югары уку йортларын һәм училищеларын тәмамлаучылар – Г.П. Анютина, А.В. Карпенко, Х. Шәрипов, Ә. Ильясова һ.б. мөрәҗәгать итә. Гобелен әсәрләре бетон һәм пыяладан төзелгән иҗтимагый биналарның интерьерларына эмоциональ төсмер бирәләр. Эре форматлы әсәрләр белән беррәттән мини-гобелен барлыкка килә. Бу жанрда А.Н. Егоров («Җайдак», 1984), А.В. Карпенко («Көзге сонет», 1984), Г.Н. Маликова («Ретро стилендә», 1983), Г.П. Анютина («Очыш», 1986) һ.б. **актив** эшли. Гобеленга татар халык сәнгатенә хас сурәтләү чаралары үтеп керә (орнаментлы бизәлеш, төсләр кушылудагы һәм образлылыктагы милли үзенчәлекләр), бу исә профессиональ татар гобелен мәктәбе барлыкка килүе турында сөйли. Орнаменталь бизәлешле гобелен М.С. Килдебәкова, Г.Н. Маликова, Х. Шәрипов, Ә. Ильясова иҗатларында аеруча киң үсеш ала. Биредә татар милли бизәкләре, **җылы, якты** төсләр палитрасы актив роль уйный. 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башында гобеленга заказлар азая, сәнгатьнең бу төренә ихтыяҗ **кими**. 1990 елларның 2 нче яртысында – 2000

еллар башында Чаллыда А.В. Карпенко, Х. Шәрипов, Е.И. Одинцова, С.В. Большакова, Казанда Ә. Ильясова гобелен әсәрләре тудыралар. Хәзерге заман гобелен сәнгатендә шартлы-символик образлар, фигураларны, пейзажларны, предметларны орнаменталь-бизәлеш юлы белән стильләштерү өстенлек итә. Х. Шәрипов әсәрләрендә татар фольклоры сюжетлары төп тема булып тора. Ә. Ильясова эшләрендә ислам сәнгате традицияләре чагылыш таба, алар Шәрык миниатюрасын хәтерләтә («Дантау тарлавыгында» диптихы, 1990; «Шәрык мотивлары», 1991). Чаллы **хатын-кыз** рәссамнарының мини-гобелен әсәрләренә гомумкешелек темалары хас (С.В. Большакова – «Юллар һәм язмышлар», 2000; Е.И. Одинцова – «Агония», «Болыт эчендә», 1999-2000). ТР рәссамнарының гобелен әсәрләре гамәли бизәлеш сәнгатенең халыкара, бөтенсоюз, бөтенроссия, төбәк, Республика күргәзмәләрендә күрсәтелә. Алар ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләре картиналар галереяләрендә саклана (Д. Валеевадан).

**Биремнәр.**

1. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең антонимнарын табыгыз һәм алар белән җөмләләр төзегез.

2. Текстның эчтәлеге белән танышыгыз, икенче абзацка исем бирегез һәм аның иң әһәмиятле өлешләрен сөйләргә әзерләнегез.

3. Татар халкының гобелен сәнгате үсешенең хронологик планын төзегез.

4. Курсив белән бирелгән сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең язылышын истә калдырыгыз сүзлек диктантына әзерләнегез.

5. Тексттан гобелен сәнгате осталарының фамилияләрен һәм сәнгать әсәрләрен язып алыгыз һәм аларның берсе турында тулырак мәгълүмат әзерләп килегез.

**Тема буенча контроль сораулар.**

1. Татар халкының нинди сәнгать төрләрен беләсез? Берсе турында тулырак итеп сөйләгез.

2. «Казан җөе» турында алган мәгълүматларыгыз белән уртаклашыгыз.

3. Татарстан территориясендә керәч эшләнмәләрнең иң әүвәлге табылдыклары кайсы дәвергә карый?

4. «Булгари» терминының нинди мәгънәләрен беләсез?

5. Татарстанда гобелен сәнгатенә кем нигез сала?

6. Татар халкының чигү сәнгатендә нинди шартлы билгеләр һәм символлар кулланылган?

7. Керәч сәнгате нәрсәләр иҗат итү өчен файдаланыла?

8. Татарстан рәссамнарының гобелен әсәрләре кайларда саклана?

9. Болгар керәч сәнгатенең үзенчәлекле формалары турында сөйләгез.

10. Татарстанда гобелен сәнгатенең чәчәк ату чорын атагыз.

**Тема буенча тәкъдим ителә торган әдәбият**

Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. Казань, 1995. 145с.

Валеевв Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969. 238 с.

Валиев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1974. 320 с.

## ДҮРТЕНЧЕ ТЕМА

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛИ КИЕМНӘРЕ

1. Татар халкының киемнәрендә миллилек.
2. Татар халкының милли баш киемнәре.
3. Татар халкының милли аяк киемнәре.
4. Татар халкында тукучылык эше

Татар халкының милли киемнәре үзләренең матурлыгы һәм зәвыклылыгы белән сәнгатебезнең **кабатланмас** үрнәге булып тора. Бербөтен һәм **искиткеч** гармонияле татар костюмында бер-берсен тулыландырып һәм баетып, кием кисү, туку, күптөрле чигү, зәркәнчелек һәм күн мозаикасы кебек сәнгать төрләре чагыла. Татар осталары камиллек, нәфислек, затлылык һәм зәвыклылык үрнәге булырлык *бик* күп гүзәл әсәрләр иҗат итеп калдырган. Татар халыкының борынгы милли киеме – чын мәгънәсендә халыкның күңел *көзге*се. *Ул* төрки халыклар тудырган тотрыклы конструктив элементларның ислам дине таләпләре нигезендә илаһи нурланышы. Алай **гынамы**, **хәтта** шигърияте, риваяте. XIX гасыр уртасына кадәр тернәкләнеп килгән татар хатын-кыз кием ансамбленең нигезендә, мәсәлән, төрки халыкларның авыз иҗаты әсәрләрендә, ырым-гадәтләрендә **шактый** нык таралган Хаума (Хома) кош образы ярылып ята. Күлмәкнең куштанлы киң итәге, аның кул-бармакларны каплаган киң җилпәзә җиңнәре, "күкрәкчә", "изү" кебек " каурыйлы", "тәңкәле" архаик түшлекләре, каюлы читекләрендәге "тырналы орнамент" һәм калфак рәсеменә кереп яткан "алтын каурый" – боларның барысы да шуны дәлилли. **Ләкин** мәҗүсилек чорында Һинд, Иран мәдәниятләреннән кергән бу образ, вакыт үтүгә, ислам дине тәэсире астында үзенең асылын югалта, "Хәят агачы" – чәчәкле-гөлле куак, бизәкле тирәк образына әверелә ("Белем.ру" сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрдә иҗек басымын билгеләгез.

2. Текстта курсив белән бирелгән сүзләрнең омонимнарын табыгыз, алар белән җөмләләр төзегез.

3. Татар халкының милли кием лексикасына караган түбәндәге сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз: *тастар, сүрәкә, яулык, аскы яулык, кирәс, калфак түбәтәй, бүрек, кәләпүш, җилән, чоба, бишмәт, чикмән, камзул, алъяпкыч, күкрәкчә.* Бишесе белән җөмләләр төзегез.

4. Югарыда китерелгән милли киемнәрдән берсен сайлап алып, рәсемен ясагыз һәм рәсем буенча сөйләргә әзерләнегез.

5. Текстны укыгыз, эчтәлеген тулыландырып, татар милли хатын-кыз киемендәге *көмеш-челтәр хәситәләр, беләзек-алкалар, муенсалар, укалы калфа*к һәм *каюлы читекләр* кебек сәнгать казанышларының берсе турында татарча презентация әзерләгез.

**Тест.**

1. Бербөтен сүзендә ирен гармониясе күзәтелә. *Дөрес/Дөрес түгел.*

2. Тәэсир сүзе – алынма сүз. *Дөрес/Дөрес түгел.*

3. Шигърият сүзендә ъ билгесе аеру функциясен үти. *Дөрес/Дөрес түгел.*

4. Зәркәнчелек “ювелирное искусство” дип тәрҗемә ителә. *Дөрес/Дөрес түгел.*

5. *Яулык* сүзендә [w] авазы һәм күтәрелмә дифтонг бар. *Дөрес/Дөрес түгел.*

## 2. Татар халкының милли баш киемнәре

Баш киеме татар милли костюмының аерылгысыз бер өлеше санала. Татар халкының баш киемнәрен ирләрнекенә һәм хатын-кызларныкына бүлеп карарга кирәк. Ирләр баш киеменең эчке (өйдә яисә бинада кию өчен) һәм тышкы (урамда йөргәндә кию өчен) төрләре бар. Эчке төренә түбәтәй, ә тышкысына **төрледән-төрле** мех яисә чүпрәктән тегелгән шапкалар, эшләпәләр һәм дини баш киеме (чалма) керә. Түбәтәйнең иң борынгы төре дүрт кисәк өлгедән **ярымсферик** формада

тегелгән. Аны формасын саклар өчен һәм гигиена максатларында (һава йөрсен өчен), юл араларына ат ялы яисә шнур тыгып калдырып, сыра торган булганнар. Яшьләр өчен бик ачык төстәге, бизәкле түбәтәйләр тегелсә, **картлар** өчен гадирәкләре тегелгән. Ә түбәтәйләрнең яңарак варианты тигез өсле булган. Аны казан татарларының шәһәрдә яшәүче өлеше кигән.

Ә **хатын-кызларның** баш киемнәре татар милли костюмын милли һәм территориаль яктан аерып торучы элемент саналган. Алар яшь **үзенчәлекләре** турында күп мәгълүмат биргән. Кызлар кия торган баш киеме шапка яисә калфак формасында булган. Чәч үремнәре тигез булып баш киеменнән чыгып торган. Әлбәттә, иң билгеле баш киеме калфак саналган. Ул **башка** махсус бәйләвеч белән киелә торган булган, ә конуска охшаган очы артка яисә янга төшерелеп киелгән. Калфакның ак киҗе мамык җепләрдән бәйләнгәне бик популяр булган. Ак калфакны күбесенчә авыл кызлары кигән, ә шәһәрдә калфакның **төрле** төстәге ефәк җепләрдән тегелгәне киелгән. Алар бай орнамент яки аппликация белән «колаклы» техникада эшләнгән.

Кияүдәге ханымнарның баш киемнәре күпкә катлаулы һәм төрле. Кызларныкыннан аермалы буларак, алар хатын-кызның муенын, җилкәсен һәм аркасын **тулысынча** капларга тиеш булган. Хатын-кызларның баш киеме төп өч өлештән торырга тиеш: эчке өлеш, төп өлеш һәм өске өлеш. Эчке өлеш чәчләрне җыеп капларга мөмкинлек бирсә, төп өлеш (аны тастар, яулык, кыекча дип йөрткәннәр) яшь үзенчәлекләрен билгеләүче төрле детальләр белән баетылган. Алар өстеннән тагын бер яулык бәйләнгән яки шапка киелгән.

XVII–XIX гасырларда тәңкәле шапкалар кигәннәр. Алар конус формасында булып, төрле ташлар белән бизәлгән, чигүле **ефәк** тукыма белән төрелгән.

Хатын-кыз баш киеменең аерылгысыз өлеше саналган тастар татарлар яши торган барлык өлкәләрдә дә популяр булган. Ул сөлге сыман ак төстәге бәйләвечтән гыйбарәт. **Бәйләвечнең** очы кызыл төстәге тасма белән бизәлгән. Шәһәрдә тастарның фабрика шартларында челтәрләп эшләнгән һәм профессиональ осталар тарафыннан чигелгән төре кулланылган (“Белем.ру” сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм иң әһәмиятле өлешләрен сөйләргә әзерләнегез.

2. Түбәндәге сорауларга язмача җавап бирегез.

*Ирләр һәм хатын-кызларның баш киемнәре ничә өлештән торган?*

*Түбәтәйне ни өчен сырып теккәннәр?*

*Ирләр баш киеме аларның яше турында сөйлиме?*

*Хатын-кыз баш киеменең үзенчәлеге нидә булган?*

*Ханымнарның баш киеме ни өчен катлаулырак?*

*Авыл кызлары һәм шәһәр кызлары бер үк төрле калфак кигәнме? Ни өчен?*

3. Калын хәрефләр белән бирелгән ясалма сүзләрнең ясалыш ысулларын билгеләгез.

4. Текстның дүртенче абзацын мәгънәсенә зыян килмәслек итеп, үзгәртеп языгыз.

5. «*Кешене – кием, агачны яфрак бизи*» дигән әйтем белән килешәсезме? Фикерегезне дәлилләгез.

6. “Милли киемнәрдә заманча рух” темасын яктыртыткан проект әзерләгез.

**Тест.**

1. Түбәтәйнең иң борынгы төре биш кисәк өлгедән тегелгән. *Дөрес/Дөрес түгел.*
2. Ак киҗе мамык җепләрдән бәйләнгәне калфак бик популяр булган. *Дөрес/Дөрес түгел.*
3. Хатын-кызларның баш киеме төп дүрт өлештән торган. *Дөрес/Дөрес түгел.*
4. Тастар өстеннән тагын бер яулык бәйләнгән яки шапка киелгән. *Дөрес/Дөрес түгел.*
5. Яшьләр өчен ачык төстәге, бизәкле түбәтәйләр тегелгән, картларның түбәтәйләре гадирәк булган. *Дөрес/Дөрес түгел.*

### 3. Татар халкының милли аяк киемнәре

Күн эшләнмәләр – традицион татар халык ................ бер төре. Бер үк вакытта кайрап һәм тукыманы бизәп башкарыла торган «Каю» дип аталган кулдан тегү катлаулы табигате аркасында бөтен дөньяда танылды.

Күн аяк киеме җитештерү сәнгате борынгы ................ чорыннан ук килә. Моңа борынгы Казан казылмаларында болгар истәлекләрендә табылган күн читекләр *шаһит*.

«Булгари» терминын күп кенә Аурупа, Урта Азия, Себер, Якын һәм *Ерак Көнчыгыш* илләре ................... «хуш ис килеп торган, төсле, югары сыйфатлы күн» дип аңлату киң таралган. Болгарларның барысы да диярлек күн итек киеп йөрүе урыс *елъязмачысы* искәрмәсеннән билгеле.

«Азия аяк киеме» атамасын алган аяк киеме традицион татар читекләрен, башмакларын ясаган Казан күнчеләре, башмакчылары *һөнәрчеләре* аркасында безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

«Казан җөе»нең киң *мәйданга* җәелүенә карамастан, XIX гасыр башы – XX гасырда Казанда һәм Казан тирәсендә үсеш алган бизәклелеге һәм төрле төсле булуы сәнгати җитештерүнең үзенчәлеге, үзенә генә хас сыйфаты булып калды.

Казан һәм аның тирәсендәге ................. генә дә XIX гасырның сиксәненче елларында көн саен өч миллион парга якын аяк киеме җитештергәннәр. Аларны һәр ике башкалага, шулай ук Англия, Франциягә сатканнар. Түбән Новгород, Ирбит, Минзәлә һәм башка ярминкәләр аркылы, читекләр Себергә, Кавказ арты, Бохарага кадәр барып җиткән. Русия һәм ............. күргәзмәләрдә алар югары бәя ала. Купец М. Галиев тарафыннан *тәкъдим ителгән* сафьян читекләр һәм башмаклар зур алтын медальгә һәм Париждагы Аурупа фәннәр *җәмгыят*е тарафыннан вензелле җиз медальгә, шулай ук 1889 елда Бөтендөнья Париж күргәзмәсенең мактаулы бәясенә һәм көмеш медаленә лаек була (“Минем йорт” сайтыннын).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз. Алынма сүзләрне язып алыгыз.

2. Күпнокталар урынына түбәндәге сүз һәм сүзтезмәләрне куеп, җөмләләрне күчереп языгыз: *халыкара, сәнгатенең, бистәләрдә, болгар-татар, телләрендә.*

3. Текст буенча төркемдәшләрегезгә 5 сорау әзерләгез.

4. Курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, сүзлек диктантына әзерләнегез.

5. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ннән *кул, аяк* сүзләренең мәгънәләрен язып килегез.

## 4. Татар халкында тукучылык эше

Тукучылык – татарларда киң таралган һәм борынгы кәсепләрнең берсе. Тукучылык өчен чимал булып җитен, ............ һәм йон кулланылган. Әлеге чималны тукыма хәленә китергәнче, халык, эшкәртү срокларын төгәл саклап, аларны төрле алымнар һәм ысуллар белән *камилләштергән*. Җитен һәм киндерне иң элек төрле формадагы талкышларда (русча – мялка) ваклаганнар. Күбрәк, ясау өчен уңайлы булганлыктан, такталы горизонталь талкышлар кулланылган. Ваклаганнан соң, җепселләрне кулдан эшләнгән *каккыч* ярдәмендә талкыштан һәм киндер сөягеннән чистартканнар, барлыкка килгән сүсне саклык белән генә *махсус* ясалган тараклар белән тараганнар. Мондый тараклар агач тактага тимер *энәләр* кагып ясалганнар. Ә сарык йонын тараганчы чүбеннән арындырып, йон или торган станокта аяганнар. Йонны эрләү өчен каба һәм орчык кулланылган. Кабаларның күп кенә формалары билгеле булган, әмма еш таралганы – җыелма каба булган, ягъни яссы тактага урнаштырылган вертикаль такта. Бу тактага йон бәйләнеп куелган. Әзер җепне тубырча дип аталган станокта аркылы һәм буй җепләргә аерганнар.

Туку станокларының формалары шулай бик күп төрле булган. Аларның рамсыз, тулы рамлылары яисә тулы булмаган рамлылары кулланылган. Бу ............ әзерләнгән тукымалар сыйфаты ягыннан да, бизәге ягыннан да, *функциональ кулланылышы* ягыннан да төрле булганнар. XIX гасыр уртасына кадәр кием тегү өчен төп материал булып киндер, постау (сукно) кулланылган. Традицион материал сыйфатында ак киндер файдаланылган. Бу киндерне төрле буяуларга буяганнар, мондый

тукымадан тегелгән күлмәкләрне ................ дип атаганнар. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында төсле буй-буй рәсемле яисә шакмаклы рәсемле киндер – алача (пестрядь) – кулланганнар. Бу алачадагы сызыкларның төсенә, үлчәменә, кулланылыш ешлыгына карап, кием хуҗасының яшен һәм җенесен белергә мөмкин булган. Ирләр киеме вак сызыклы тукымадан тегелсә, .................. киемендә эре бизәкләр, зәңгәр, яшел, сары һәм ак төсләр белән чиратлашучы кызыл киң полосалар еш файдаланылган. Шакмаклы рәсемле тукымалардан күбрәк эчке кием теккәннәр.

XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында тукучылык төрле бизәкләр куллану белән характерлана. Бизәкләр эре дә, вак та, төсләр палитрасы да бай булган. Йорт шартларында тукылган тукымалардан урын-җир, сөлгеләр, эскәтер һәм пәрдәләр тегелгән. Аларның урта өлеше гади үрелеп тукылса, башлары полосалар белән бизәлгән. Кайбер тукымаларны аз сандагы такталар кулланып, төрле бизәк ясап та тукыганнар. Андый ............. йөзек кашы, уймак чүпләм дип аталганнар. Татарларда борын-борыннан билгеле булган чыбылдыклар да шул техника белән тукылган. Татарлар катлаулы техника (һәр орнаменталь форма аерым җепләр белән) белән башкарылган кырык шырпылы тукымалар ясау белән дә *шөгыльләнгәннәр* (“Белем.ру” сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Түбәндәге сүзләрне тиешле урыннарга куеп, текстны укыгыз: *хатын-кызлар, станокларда, киндер, бизәкләр, буяу күлмәк.*

2. Кушма нигезле сүзләрне бер баганага, сүзьясагыч кушымчалыларын икенче баганага язып төшегез.

3. Курсив белән бирелгән сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз, алар белән яңа җөмләләр төзеп языгыз.

4. Өч абзацның берсен сайлап алып, үзгәртеп языгыз һәм шул өлешкә исем куегыз.

5. “Татар халкының милли өс киемнәре” темасына презентацияле чыгыш ясарга әзерләнегез.

**Тема буенча контроль сораулар.**

1. Тукучылыкта талкы нинди роль үтәгән?

2. Тукыма сыйфатына станоклар тәэсир ясаганмы?

3. Нәрсә ул буяу күлмәк?

4. Тукучылык кайчан һәм ничек камилләшкән?

5. Ирләр киеме өчен булган тукымалар хатын-кызларныкыннан нәрсәсе белән аерылган?

6. Ирләр һәм хатын-кызларның баш киемнәре нинди өлешләрдән торган?

7. Ирләр баш киеменең үзенчәлекләре турында сөйләгез.

8. Хатын-кыз баш киеменең үзенчәлеге нидә булган?

9. Борынгы киемнәр бизәлешендә киң таралган Хаума (Хома) кош образы турында нәрсәләр беләсез?

10. Баш киеме аша кызларның яшь үзенчәлекләрен билгеләп булганмы?

**Тема буенча тәкъдим ителә торган әдәбият.**


1. Ахметова Д.И. Проблема стилевого многообразия в ситуации современной художественной культуры. Казань: ИЯЛИ, 2014. 184 с.

2. Валеева Д.К. Искусство Волжской Булгарии // Искусство народов СССР: В 10 томах. Т.3. М..1974. 178с.

3. Белем.ру. http://belem.ru

4. http://senior-danif.narod.ru/index/0-9

5. https://tt.wikipedia.org/wiki

БИШЕНЧЕ ТЕМА

## ТАНЫЛГАН СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ

1. Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге.
2. Татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы сынчы, нәкыш остасы – Бакый Урманче.
3. Татар графикасында җуелмас эз калдырган рәссамнар.
4. Күренекле кылкаләм осталары.
5. Агачтан уеп декоратив-нәкыш ясаучылар һәм монументаль рәсемнәр иҗат итүчеләр.
6. Күренекле каллиграф – Нәҗип Нәккаш.

**1. Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге** – рәссам һәм сәнгать белгечләренең иҗади җәмәгать оешмасы 1935 елның 3 августында Татарстан өлкә комитеты бюросы карары белән оештырыла. Уставы 1936 елда раслана. Әлеге оешма төрле елларда төрле исемнәр йөртә:1935-1937 елларда – ТАССР Совет рәссамнары берлеге; 1957-1960 елларда – СССР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлеге; 1968-1992 елларда – ТАССР Рәссамнар берлеге; 1992 елдан Татарстан Республикасының рәссамнәр берлеге. Бүгенге көндә Татарстанда биш рәссамнар берлеге теркәлгән:

1. “Россия рәссамнар берлеге”нең Татарстандагы оешмасы (рәисе – Виктор Аршинов, 169 әгъза исәпләнә);
2. “Татарстан рәссамнар берлеге” иҗтимагый оешмасы (рәисе – Зөфәр Гыймаев, 116 әгъза);
3. “Россия рәссамнар берлеге”нең Чаллыдагы бүлеге (рәисе – Факил Гайфетдинов, 42 рәссам Россия рәссамнар берлеге әгъзасы булып тора, 18 рәссам – Татарстан рәссамнар бүлеге әгъзалары).

4. “Татарстан Республикасындагы Россия рәссамнары иҗади берлеге” төбәкара бүлеге (рәисе – Илгизәр Самакаев, 58 әгъза).

5.“БДБ илләре профессиональ рәссамнарының Казандагы бүлеге” (рәисе – Лада Аюдаг, 104 әгъза).

Татарстан Республикасы рәссамнарының иҗади берлекләре белән хезмәттәшлек итү максатыннан, 2014 елның гыйнвар аенда Мәдәният министрлыгы каршында рәссамнарның координацион берлек советы төзелде. Координацион советның рәисе – Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин. Рәсем сәнгатен үстерү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыру ниятеннән иҗади берлекләрнең эшчәнлеген күзәтү, рәсем сәнгате буенча күргәзмә проектларын әзерләү һәм тормышка ашыру, рәссамнарның иҗади берлекләренә бәйле сорауларын хәл итү әлеге советның төп эше булып тора. Татарстан Мәдәният министрлыгы каршында сәнгать-эксперт советы эшли. Ул рәссамнар һәм сәнгать белгечләреннән төзелгән. Татарстан музейлары фондларын тулыландыру максатыннан, картиналар сатып алу карары шушы советта раслана (“Татар энциклопедия сүзлеге”ннән).

## 2. Татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы сынчы, нәкыш остасы – Бакый Урманче

**Бакый Урманче** – татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы, рәссам, график, скульптор һәм архитектор, Татарстанның һәм Русиянең халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты. Бакый Урманче 1897 елның 23 февралендә Казан губернасының Тәтеш өязе Күл-Черкен авылы.....туа.

1907–14 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсә....... белем ала. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында армиягә алына. Казахстанга эләгеп, анда Австрия әсирләреннән рәсем сәнгате буенча беренче дәресләр ала. 1919 – 1920 елларда Казандагы художество училищесында укый. 1920 елда ВХУТЕМАСка укырга кереп, аны 1926 елда тәмамлый.

1926 –1941 елларда Казанда, Мәскәүдә, Донбасста эшли. Б. Урманче көнкүреш һәм портрет жанры..... күбрәк иҗат итә

(«Сепарат янында», «Самавыр янында», «Җилкәнле көймәдә йөзү» һ.б. рәсемнәре).

1949 елларда Үзбәкстанда яши, Урта Азия табигатенә бәйле тематик картиналар, пейзаж, этюдлар яза. Балхаш бакыр эретү заводы Мәдәният йортының архитектурасы проекты һәм декоратив бизәлеше авторы (1952). 1949-1958 елларда Ташкент театр-сәнгать институтында сын сәнгате бүлеген оештыручыларның берсе була (1956).

Б. Урманченың төп әсәрләреннән “*Сагыш”* (1966), “*Та тарстан”*триптихе (1976, 1985), *Салтык болыны* (1979), “*Язгы моңнар* “(1968), “*Тулпар*”(1968), Татар мәдәнияте әһелләре портретлары, Татарстанның Кырлай авыл....
Габдулла Тукайга мемориал архитектура комплексы (1976),
Дәрдмәнд һәм Тукай шигырьләренә график иллюстрацияләр (1954-1968); балаларга сәнгать тәрбиясе бирүгә багышланган татарча беренче дәреслек (Мәскәү, 1924), рәсем сәнгатенә караган мәкаләләр һ.б.

Б. Урманче мирас итеп татар мәдәнияте эшлеклеләренең скульптура портретлары галереясен калдырды, алар арасында урта гасырлар шагыйре К. Гали, мәгърифәтче Ш. Мәрҗани,
К. Насыйри, шагыйрь Дәрдмәнд, язучы Фатих Әмирхан, Муса Җәлил һәм башкалар да бар (“Википедия” сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм әһәмиятле өлешләрен сөйләргә әзерләнегез.
2. Күпнокталар урынына тартымлы исемнәрнең урын-вакыт килеше кушымчаларын куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.
3. ВХУТЕМАС аббревиатурасын аңлатып бирегез.
4. Б.Урманче лаек булган бүләкләр һәм исемнәрне атагыз.
5. Б.Урманченың бер әсәре турында сөйләргә әзерләнегез.

## 3. Татар графикасында җуелмас эз калдырган рәссамнар

Фаик Таһиров элекке Свияжск өязенең Олы Ачасыр авылында укытучы семьясында туа. Унбер яшеннән ятим кала һәм үз көнен үзе күрергә мәҗбүр була. Башта ул Казанга килә, аннары Екатеринбургка юл тота. Шунда жидееллык рус мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә укуы белән бер ук вакытта йомышчы малай хезмәтен дә үти, китаплар төпләү белән дә шөгыльләнә. 1920 елда Екатеринбург татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә. Анда бер ел укыганнан соң шунда ук художество-тимерчелек остаханәләренә эшкә керә. Аннары Пролеткультның, изостудиясендә эшли башлый һәм шунда сәнгать буенча дәресләр ала башлый.

1922 елның апрелендә, сәнгать-техника институтына укырга керү нияте белән, Фаик Таһиров Казанга килә. Ләкин бу институтта уку бәхетенә икенче елның көзендә генә ирешә. Ул елларда инде китап басуның техник шартлары да сизелерлек яхшыра башлый. Мәскәүдә һәм Ленинградта графика сәнгатен көнкүрештә дә куллану алымнарының, бик яхшы үрнәкләрен күрсәтә торган рәссам-графиклар үсеп чыга.

Егерменче еллар башындагы татар графикасының, инде әйтеп үткәнебезчә, уңышлары шактый зур. Ләкин, шуның белән беррәттән, аның бер үзенчәлекле кимчелеге дә булган. Хикмәт шунда, ул еллар графикасында кеше һәм гомумән тере җан ияләренең сурәтләре бөтенләй диярлек чагылдырылмаган. Хәтта талантлы рәссам Фаик Таһиров та кешеләр сурәтен үзе ясамыйча, коллаж алымы (рәсем өстенә кешеләрнең әзер сурәтләрен ябыштырып куюны шулай дип атыйлар) белән генә эш иткән.

Еллар үтү белән, үз рәссамнарыбыз да кеше сурәтләрен ясаудан тартынмый башлыйлар. Шулай итеп, безнең үзебезнең график-портретчыларыбыз барлыкка килә. Әнә шундыйларның иң беренчесе итеп Дмитрий Красильниковны санарга кирәктер. Минзәлә өязенең Урта Пенәче авылында керәшен татары семьясында туган Дмитрий авыл мәктәбен тәмамлаганнан ары Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә, ләкин, сәнгатькә омтылышы зур булганлыктан, 1922 елда Пермь сәнгать остаханәсенә китә. Анда бер ел эшләгәннән соң Казанга сәнгать-техника институтына кайта. Шунда 1927 елга кадәр сәнгать белән

шөгыльләнә, аннары Мәскәүгә барып, ВХУТЕМАСта (Югары сәнгать-техника остаханәләре) укый.

Красильников иҗатына бәя биреп, профессор П. Дульский менә болай дип яза: «Аның әсәрләренең стиле реалистик. Яраткан темасы – авыл, табигать һәм кешеләр. Д. Красильниковның графика техникасы күңелгә ятышлы, йомшак һәм төзек композициягә ия».

Татар рәссам-графиклары башлап җибәргән эстафетаны егерменче еллар ахырында Казан сәнгать техникумын тәмамлаган яшь рәссамнар Ш. Махәммәтҗанов, Г. Юсупов, Г. Кәримов һәм башкалар кабул итеп алдылар һәм уңышлы дәвам иттерделәр. Монда без, урын кысан булганлыктан, аларның тик берсенең – Татарстан китап нәшриятында озак еллар буена эшләп килгән һәм китапларны сәнгатьле итеп формалаштыру эшен яхшырту өчен күп хезмәт куйган Шакир Мөхәммәтҗановның бер эшен генә урнаштырабыз.

Утызынчы елларда графика өлкәсендә Байназар Альменов кебек осталар эшли башлый. Ә соңгы ун-унбиш елда бу өлкәдә яшь рәссамнардан Илдар Әхмәдиев, Тавил Хаҗиәхмәтов, Азат Садыйков, Эрот Зариповлар бик уңышлы эшләп киләләр (Ф. Валивтан).

**Биремнәр.**

1. Текстның эчтәлеге белән танышыгыз, саф кушма сүзләр кулланылган җөмләләрне язып алыгыз.
2. Курсив белән бирелгән сүз һәм сүзтезмәләрнең язылышын истә калдырыгыз, аларны рус теленә тәрҗемә итегез.
3. Текстка нигезләнеп, Мөхәммәт Арсланов иҗатынның хронологик планын төзегез.
4. Дүртенче абзацтагы җөмләләрне, мәгънәләренә зыян килмәслек итеп, үзегезчә үзгәртеп языгыз.
5. Театр рәссамнарыннан тагын кемнәрне беләсез? Берсе турында сөйләргә әзерләнегез.
6. Текстта телгә алынган М.В. Нестеров исемендәге Сынлы сәнгать музее турында мәгълүмат (50-70 сүз) язып килегез һәм сөйләргә әзерләнегез.

**4. Күренекле кылкаләм остасы – Канәфи Нәфыйков**

Татар рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Канәфи Абзалетдин улы Нәфыйков 1938 елда Казан сәнгать училищесының театр бүлегендә **һәм** Ташкент театр сәнгать институтында белем ала. Үзбәкстанда у кый, биредә Көнчыгыш мөселманнары тарихын, урта гасырлар сәнгатен тирәнтен өйрәнә. Казанга кайткач, күренекле рәссам Бакый Урманче белән аралаша. Бу аңа һөнәри үсеш һәм тормыш мәктәбе була.

Канәфи Нәфыйков 40 елга якын гомерен тарихи рәсемнәр ясауга багышлаган. Ул болгар-татар тарихын **гына түгел**, аның сәнгати елъязмасын киндергә иңдерә. Мәсәлән, «Борынгы төркиләр. Ханның халык алдында ант итүе» картинасында хан хакимиятен кабул итеп алуның **гаять** тирән мәгънәсен аңлата торган йоласы **белән** танышырга **мөмкин**.

Рәссам тарихи портретлар язу өлкәсендә **дә** зур уңышка ирешә. Мөхәммәдьяр, Габделҗаббар Кандалый, Габдерәхим Утыз Имәни, Кәрим Тинчурин, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов кебек шәхесләрнең портретларын ясый.

Шулай **ук** Канәфи Нәфыйков Тукай образын үзенчә сурәтли. «Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев», «Тукай һәм Хөсәен Ямашев», «Тукай һәм беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская» картиналарында рәссам иҗатына гына хас чалымнар **бар**. Кайбер башка шәхесләр хөрмәтенә иҗат ителгән портретлары: Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче, Шамил Монасыйпов, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Тәлгать Галиуллин, Зәки Зәйнуллин (“Wikipedia.ru” сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, тексттагы иң әһәмиятле төп фикерләрне әйтегез.

2. Сүзләрне тиешле тәртиптә куеп, җөмләләр төзегез.

1) *Туган, Канәфи, өйрәнү, халкының, Абзалетдин, чыганагы, улы тарихын, һич, өчен, саекмас, иҗат.*

2) *Көнкүреш, өчен, да, тарихи, һәммәсе, вакыйгалар, аерым, шәхесләр, язмышы, һәм, милли, һәм, бөек, затлар, һәм, гади, кешеләр, бердәй, мөһим, яшәеш, рәссам, барысы.*

3) *Якын, ул, тарихи, 40 елга, ясауга, гомерен, картиналар, багышлаган.*

4) *Болгар-татар, К.Нәфыйков, киндергә, аның, тарихын, сәнгати, гына, түгел, елъязмасын, иңдерә.*

3. Калын хәрефләр белән бирегән сүзләрне нинди уртаклык берләштерә? Җөмләдә алар нинди вазифа башкаралар?

4. Г.Ф.Саттаровның "Татар исемнәре сүзлеге"ннән кеше исемнәре һәм фамилияләре белән бәйле ялгызлык исемнәрнең мәгънәләрен язып килегез. Үзегезнең исем-фамилиягез турында да шундый ук мәгълүмат булдырыгыз

5. Канәфи Нәфыйков портретларын ясаган шәхесләрнең берсе турында чыгыш әзерләгез.

**5. Агачтан уеп декоратив-нәкыш ясаучылар һәм монументаль рәсемнәр иҗат итүчеләр**

Әхсән Фәтхетдинов иҗатының башлангыч этабы агачтан уеп декоратив-нәкыш ясауга һәм Түбән Каманың архитектура ансамбльләре интерьерларында монументаль рәсемнәр иҗат итүгә багышлана. Әхсән Сәрим улы иҗат иткән әсәрләр Түбән каманың үзенчәлекле символы булып торалар. **Ул** күп кенә объектларны, җәмәгат биналарын бизәкләп эшләүдә катнаша. **Алар** арасында – музыка училищесе, энергетика-төзелеш техникумы, «Бигеш» аэропорты, «Кама» кунакханәсе, атракционнар паркы, «Әкият» кафесы, балалар бакчалары бар.

Әхсән Фәтхетдиновның иҗаты бик үзенчәлекле. **Аның** әсәрләрендәге төп темаларның берсе – Габдулла Тукай тормошы һәм иҗаты. Рәссамның бик күп рәсемләре һәм скульптур композицияләрендә шагыйрь Г. Тукай **үзе** һәм аның әсәрләрендәге геройлар урын ала. Ә. Фәтхетдинов **үзенең** үзенчәлекле дөньясын булдырып, шуны татар мәдәниятының табигый бер өлешенә әйләндерә. Агач, пластика һәм рәсем сәнгатенең башка өлкәләрендә иҗат ителгән хезмәтләрендә татар халкының бай мифологик мирасы һәм сынлы сәнгатнең бүгенге чаралары уңышлы үрелә. 2012 елның 15 июлендә якты дөнья белән хушлаша ("Wikipedia.ru" сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Түбәндәге җөмләләрне логик эзлеклелек сакланырлык итеп, тиешле тәртиптә урнаштырыгыз. Әлеге мәгълүматларны текстның кайсы өлешенә урнаштырыр идегез?

*Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетында укый. 1969 елда Татарстанга кайта һәм 30 елдан артык биредә, Түбән Кама шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Самара өлкәсенең Камышлы татар педучилищесында белем ала. Танылган татар рәссамы, сынчы, Татарстанның халык рәссаме, Русия Рәссамнар берлеге әгъзасы Әхсән Сарыйм улы Фәтхетдинов 1939 елның 7 июнендә Чирмешән районы Үтә меш авылында туа. Аннан соң берникадәр вакыт укытучы булып эшли.*

2. Текстны укыгыз, эчтәлеге буенча биш сорау төзегез һәм төркемдәшләрегез белән әңгәмә корырга әзерләнегез.

3. Асларына сызылган сүзләргә игътибар итегез, язылышы дөрес булмаганнарын дөресләп, җөмләсе белән күчереп языгыз

4. Текстта калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр нинди сүз төркеменә керәләр? Аларны килеш белән төрләндерегез.

5. Агачтан уеп декоратив-нәкыш ясаучылар һәм монументаль рәсемнәр иҗат итүчеләрдән тагын кемнәрне беләсез? Берсе турында тулырак мәгълүмат табып, текстны тулыландырыгыз.

**Тест.**

1. Ә. Фәтхетдинов Түбән Кама педагогия институтының сәнгать-графика факультетында укый. *Дөрес/Дөрес түгел.*
2. Ә. Фәтхетдинов иҗатының башлангыч этабы агачтан уеп декоратив-нәкыш ясауга багышланган. *Дөрес/Дөрес түгел.*
3. Ә. Фәтхетдиновның скульптур композицияләрендә шагыйрь М. Җәлил һәм җәлилчеләр урын алган. *Дөрес/Дөрес түгел.*
4. Ә. Фәтхетдинов күп кенә объектларны, җәмәгать биналарын бизәкләп эшләүдә катнаша. *Дөрес/Дөрес түгел.*
5. Ә. Фәтхетдинов утыз елдан артык Самара өлкәсендә яши һәм иҗат итә. *Дөрес/Дөрес түгел.*

### 6. Танылган каллиграф – Нәҗип Нәккаш

Каллиграфия – мәңгелек *хакыйкатьләргә* төшенү юлы. Нәҗип Нәккаш – **узган** гасырның туксанынчы елларында, иң беренчеләрдән булып каллиграфия сәнгатен **яңартуга алынган** *шәхес*. Остазы итеп ул Бакый Урманчены саный. Университетның беренче курсында укыганда ук профессор, әдәбият белгече Хатип Госман киңәше белән Бакый Урманче янына килә, аннан дәресләр ала, гарәпчә чыганакларны өйрәнә, архивларда актарына. Халык тормышын, рухын яхшы **белгән** рәссам *шәмаилләр, тугралар,* нәсел агачы – *шәҗәрәләр* эшли. Кешенең холкын, эш-шөгылен **өйрәнеп**, күңел биреп, җан җылысын биреп **ясалган** тугралар гаилә, нәсел тамгасына әйләнә. Аларның формасы да *гаять* кызыклы, хәреф һәм сүзтезмәләрдән мәчет, кораб, аккош, скрипка ачкычы сурәтләре килеп чыга. Аның үзенең туграсы очыштагы күгәрчен сурәтендә. Эшләреннән яктылык, киләчәккә ышаныч бөркелеп тора. *Куфи язуы*, гарәп графикасы серләренә **төшенгән** Нәҗип Исмәгыйлев татар традицион каллиграфиясен нигез итеп алып, XX йөз ахыры татар сәнгатендә үз мәктәбен булдыру дәрәҗәсенә ирешкән зур рәссам булып өлгерде. Н. Нәккаш 1000нән артык тугра авторы, шуларның 400дән күбрәге пыялада **эшләнгән**. Мондый күләмле иҗатны бары тик төрле яктан әзерлеге **булган** галим кеше генә башкара ала. Ул үзе дә: “Монда гарәп язуын да су урынына **эчәргә** кирәк, монда *Коръәнн*е дә, хәдисләрне дә, гомумән, тарихны да яхшы белү сорала. Фарсы телен белү дә зарур. Сәнгатьнең бу төре әдәбият һәм дин белән дә катнашкан. *Йолалардан*, традицияләрдән дә хәбәрдар булуың мәслихәт. Әлбәттә, һәрбер рәссам боларның барысын да булдыра алмый. Шунлыктан әлеге сәнгать – хаттатлык иҗаты серләре сирәк каләм ияләренә генә ачылучан”, – ди. Аның күргәзмәләрен казанлылар гына түгел, Иран, Франция, Төркия халкы да кинәнеп карый (“Wikipedia.ru” сайтыннан).

**Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, эчтәлеге буенча биш сорау төзегез һәм төркемдәшләрегез белән әңгәмә корырга әзерләнегез.

2. Текстта калын хәрефләр белән бирелгән фигыльләрнең төрләрен билгеләгез. Алар арасында күп кулланылган фигыль төрен ачыклагыз һәм җөмләләре белән күчереп языгыз.

3. Курсив белән бирелгән сүзләрнең дөрес язылышын истә калдырыгыз, сүзлек диктантына әзерләнегез.

4. Үзегезнең нәсел шәҗәрәсен төзеп, “Шәҗәрәмдә нәселем тарихы” исемле конкурска әзерләнегез.

5. Каллиграфия яки шәмаиллар турында 8 слайдтан да ким булмаган презентация әзерләгез.

**Тема буенча контроль сораулар**

1. Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге кайчан оештырылыла?

2. Мәдәният министрлыгы каршында рәссамнарның координацион берлек советы кайчан төзелә? Әлеге советның рәисе кем?

3. Бакый Урманче иҗаты татар сынлы сәнгате үсешенә нинди йогынты ясаган?

4. Б.Урманченың нинди сәнгать әсәрләрен беләсез?

5. Бакый Урманче Канәфи Нәфыйков һәм Нәҗип Нәккашл белән таныш буламы?

6. К. Нәфыйков кайсы тарихи шәхесләрнең портретларын иҗат иткән?

7. Канәфи Нәфыйковның тагын нинди әсәрләрен беләсез?

8. Нәҗип Нәккаш кем ул? Нинди сәнгать әсәрләре аша халыкка таныла?

9. Әхсән Фәтхетдинов иҗат иткән сәнгать әсәрләрен атагыз? Бу юнәлештә эшләүче тагын кемнәрне беләсез?

10. Д. Красильников, Б. Альменов, Ш. Мөхәммәтҗанов, Г. Юсупов, Г. Кәримов И. Әхмәдиев, Т. Хаҗиәхмәтов, А. Садыйков, Э. Зарипов кебек сәнгать осталарының берсе турында тулырак итеп сөйләгез.

**Тема буенча тәкъдим ителә торган әдәбият.**

Художники Татарстана: Справочник посвящается 75-летию Союза художников Татарстана. Казань: Изд-во “Заман”, 2011. 308 с.

## КУШЫМТА

## УКУ ҺӘМ АРАЛАШУ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

**Лотфулла Әбделмән улы Фәттахов** – татар рәссамы, Русиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның Дәүләт, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. 1918 елның 27 сентябрендә Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районы Анды авылында туа. Әтисе Гражданнар сугышында, әнисе 1926 елда ачлыктан вафат булгач, 4 бертуган ир-бала ятим калалар. Лотфулла әдәби әсәрләре һәм рәсемнәре "Пионер каләме" газетасында басыла, беренче уңышларыннан канатланган малай, җәяүләп Казанга укырга чыгып китә. Лотфулланы Маһикамал һәм Габдрахман Якуповлар үзләренең 6 баласы һәм тәрбиягә алынган бер кыз бала өстенә сигезенче итеп уллары Харисның мәктәп дусты Лотфулланы уллыкка ала. Булачак ике рәссам рәсем түгәрәгенә йөри. Лотфулланың әдәбият белән мавыгып, "Әдәбиятчы" дивар газетасына хикәяләр яза, рәсемнәр ясый. Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 елдан Татарстан художество фондында эшли. 1960-1968 елларда РСФСР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы һәм аның сәркатибе була. Танылган иҗат әсәрләре «В.И. Ленин Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куя» (Харис Якупов белән бергә), «Ватан турында җыр», «Игеннәр өлгерде», «Яңа бура», «Яшьлек», «Сабантуй» (1957), «Мулланур Вахитов», «Шәһәрдән кайту» һ.б.

**Илдар Касыйм улы Зарипов**

Илдар Касыйм улы Зарипов – татар рәссамы, Русиянең һәм Татарстанның атказанган рәссамы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, рәссамнар берлеге әгъзасы.

И. Зарипов 1939 елда Казанда туа. Казан сәнгать училищесын һәм В.И.Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать институтын тәмамлый. 1968-1970 елларда Сәнгать академиясендә СССРның халык рәссамы Г.М.Коржева җитәкчелегендә рәсем остаханәсендә стажировка үтә. 1970 елдан Россия рәссамнар берлеге әгъзасы.

1970 елдан алып И.Зарипов Казанда яши һәм эшли. Аның үзенчәлекле иҗаты Россия рәсем сәнгате тарихына кергән, аеруча 1960–1980 елларда ясалган «Өйдә» (1971), «Нефтьче Әхәт абый» (1974), «Казан чибәре Зөлфия» (1984), «Катюша», «Батыр» (1985), «Кырлай моңы» (1986, 1988), «Авылда» (1987), «А.С.Пушкин» сериясеннән пейзажлар» (1980 еллар) кебек гүзәл әсәрләре киң танылган. 1990 елларда ул – Татарстанда әйдәп баручы рәссамнарның берсе, Россия һәм чит илләрдә танылу ала.

2004 елда Илдар Зариповның юбилеена мөнәсәбәтле Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевтан бүләк буларак, Казанда галерея студиясе ачылды.

**Ринат Мансур улы Анимаев** – совет һәм француз рәссамы. 1989 елдан Франциядә яшәп, иҗат итә. Мәскәү рәссамнары берлеге, Франция рәссамнар берлеге әгъзасы. Монмартрның мактаулы гражданы. 1955 елның 24 мартында Дүшәнбе шәһәрендә рәссам Мансур Анимаев гаиләсендә туган. Дүшәнбе шәһәрендә сәнгать мәктәбен, сәнгать укуханәсен, Мәскәүдә Суриков исемендәге дәүләт сәнгать институтын тәмамлаган (1984). 1989 елдан Франциядә яшәп, иҗат итә. Остаханәсе Париж үзәгеннән 14 км ераклыктагы Ивелин департаменты Вирофле шәһәрендә урнашкан.

Ринат Анимаев сынлы сәнгатьнең графика, портрет, тарихи портрет, аеруча пейзаж һәм натюрморт жанрларында һәм стильләрендә иҗат итә. Шулай ук скульптура сәнгате буенча хезмәтләре бар. Рудольф Нуриев, Лев Гумилев, Людмила Гурченко, Владимир Высоцкий, Александр Солженицын, Равил Бохараев портретларын ясаган.

**Илдус Гайнетдинов** – рәссам һәм модельер-конструктор, Франция һәм Алманиядәге халык сәнгате күргәзмәләрендә катнашучы, Арча фабрикасының экс-директоры. Борынгы һөнәрчелекне саклау юлларын эзли. 1999 елда ул хатыны Әлфия Артемьева белән Дөбьяз авылындагы һөнәрчелекнең соңгы осталарын җыеп, «Сахтиан» шәхси фирмасын ача. Читекләр, башмаклар, янчыклар, букчалар, курткалар, телефон савытлары, Корьәннән сурәтләр төшерелгән композицияләр халык арасында популярлык казана. Читекчелек һөнәрен дәвам итеп, И. Гайнетдинов компазицион басымны кыю үзгәртә, бизәкләргә яңа сулыш өрә. Тикшерүчеләр И. Гайнетдинов читекләренең үзенчәлеге бизәкләрнең һәм төп җирлекнең үзара кушылып китүендә дип саный.

**Абрек Әмир улы Абзгильдин** 01.03.1937 туа. Татарстан Республикасының халык рәссамы (1995), Россия сәнгать Академиясенең әгъза-мөхбире, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1997), Россиянең атказанган рәссамы (2002), Россия сәнгать Академиясенең көмеш медале белән бүләкләнә (2003). Рәсем сәнгате, графика, декоратив-гамәли сәнгать кебек төрле жанрга караган әсәрләре белән танылган. А.Абзгильдин Татарстанның монументаль сынлы сәнгать осталарыннан да санала. Аның мозаикалары, стена рәсемнәре, керамикадан эшләнгән монументаль-декоратив композицияләре Казан, Лениногорск, Бөгелмә, Чаллы, Салават шәһәрләренең биналарын бизәп тора.

Күренекле рәссам **Харис Габдрахман улы Якупов** 1919 елның 23 декабрендә Казанда эшче гаиләсендә туа. Мәктәптә укыганда ук сынлы сәнгать студиясенә йөри, күргәзмәләрдә катнаша. «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында рәсемнәрен бастыра. 1939 елда Харис Якупов Казан сәнгать училищесын тәмамлый. 1939-1945 елларда армия сафларында, Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр фронтта алгы сызыкта, ут эчендә була. Харис Якупов Мәскәү янында, Курск дугасында, Украина, Польша, Чехословакияне азат итү сугышларында катнаша. Анда да рәсем ясаудан туктамый, фронт газеталары өчен сатирик рәсемнәр ясый, көндәлекләр алып бара. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

Харис Якупов – танылган портрет остасы. Ул ясаган Г.Тукай, А.Пешков, Ш.Камал портретлары аеруча уңышлы дип табыла. «Г.Тукай крестьяннар арасында», «А.С.Пушкин Казан юлында», «А.М.Горький Марусовкада» (1946-1949) кебек картиналары тарихи темаларга багышлана. Харис Якупов – пейзажчы да. Ул «Иделдә эссе көн», «Казанкада су ташу», «Кабан күле», «Иделдә яз», «Зур Идел» кебек зур полотнолар иҗат итә.

**Илдар Мәнсәви улы Ханов** 1940 нчы елда Татарстан Республикасының Иске Аракчино бистәсендә туган. 1960 нчы елда Казан сәнгать училищесен тәмамлаган, Мәскәүдә В.Суриков исемендәге сәнгать институтында белем алган. Сугышка каршы эчтәлектәге әсәрләр, галәмне яулау турында һәм башка бөек вакыйгаларга багышланган 150 рәсем ясаган Илдар Ханов институт тәмамлагач та (1968), СССР рәссамнар берлегенә кабул ителгән.

И.М.Ханов күпкырлы иҗади шәхес. 40 ел дәвамында ул 70тән артык скульптура һәм монумент-декорация әсәрләре, йөзләп картина ясаган. Бүген аның иң яхшы эшләре Россия музейларын, шулай ук Татарстанның күп шәһәрләренең урамнарын һәм мәйданнарын бизи.

**Рәссам Илгизәр Хәсәнов** – шәһәрнең сәнгать тормышында күренекле шәхесләрнең берсе. Аның идәннән түшәмгә кадәр борынгы әйберләр белән тулы остаханәсен, асылда, югалган Казанның музее, дип атап була. Илгизәр – шәһәренең патриоты, сагынып искә алырлыгы гына калган шәһәр тормышының күпсанлы «шаһит»ләрен саклап калган кеше.

Илгизәр Хәсәнов «иҗат юлын» 1980 нче еллар ахырында шәһәр чараларында актив катнашудан башлый.

2000нче елларда ул бер-бер артлы биш шәхси күргәзмәсен оештыра: «Муха» (2007), «Чёрное озеро» (2008), «Удар» (2008), «Моя Япония» (2009), «Территория абсурда» (2010).

Рәссам иҗатында мөһим урынны объект һәм инсталляция алып торса да, ул рәсем сәнгате белән шөгыльләнүне дә читкә куймый. Хәсәнов еш мөрәҗәгать итә торган төп тема – балачак. Икенче тема итальян «метафизик» рәсем сәнгате белән бәйле. Илгизәр Хәсәнов рәсемнәренең күбесендә шартлы шәрык шәһәрләрендә яшәүче серле кешеләр сурәтләнгән.

Параллель рәвештә И. Хәсәнов урау юллар аша киногa якынлаша: сюжетлы фотографияләр циклларын, анимация элементларын файдаланып видеоклиплар төшерә. 2007 елдан башлап, Илгизәр Хәсәновка Татарстан киносында куючы рәссам буларак таныла.

**Айрат Габдулла улы Хәмидуллин** — күренекле педагог, пост-импрессионизм стилендә иҗат итүче танылган рәссам.

Айрат Хәмидуллин 1956 елның 20 гыйнварендә Казан шәһәрендә туган. Кечкенә чактан ук рәсем ясарга яраткан. Рәсем мәктәбен тәмамлагач, Казан Сынлы Сәнгать Училищесына укырга керә. Училищены кызыл диплом белән бетергәннән соң, Суриков исемендәге Мәскәү Дәүләт Академия Рәсем Институтына укырга керә. Уку вакытында музейларда пост-импрессионист эшләреннән күчермәләр ясый. Шушы стиль белән мавыгып китә. Рәссамның иҗатында табигать күренешләре, натюрмортлар һәм башка жанр композицияләре чагылыш таба. Аның «Иске Казан урамнары» сериясе күргәзмәгә килүчеләрне аеруча сокландыра.

1986 елдан башлап Казан сынлы сәнгать училищесында укыта. Рәссам Айрат Хәмидуллин 1996 елдан бирле Татарстан

Рәссамнар берлеге әгъзасы, 2002 елда исә Русия Рәссамнар берлегенә кабул ителә. Аның рәсемнәре Татарстан Республикасы, Русия, Америка, Алмания, Франция музейларында һәм шәхси коллекцияләрдә саклана.

**Латыйф (Латыйпов) Хәмит Нәҗип улы**

Рәссам-шагыйрь, агачтан уеп эшләүче, график, сыннар ясаучы һәм җитен тукымага майлы буяулар белән рәсем төшерү остасы. 1998 елдан Русиянең Рәссамнар берлеге. 2002 елдан Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы.

Хәмит Латыйф 1949 елның 5 мартында Пермь өлкәсе, хәзерге Губака шәһәрендә туган. Шул ук елны аларның гаиләсе Башкортстанның Илеш районы Бүләр авылына кайта. Хәмиткә 7 ай вакытта әнисе дөнья куя, 13 яшьтә әтисен дә югалта. 1964 елда Башкортстанның Илеш районы Тыпый авылында сигезьеллык татар мәктәбен тәмамлый һәм Уфа музыка-педагогия училищесына укырга керә.

1972-1973 елларда Мәскәү янындагы Загорск районының Богородск авылында агачтан уеп эшләүнең махсус алымнарын үзләштерә. 1974-1978 елларда Уфа сәнгать училищесында укып, художник (мастер-кисүче) дипломы ала һәм Татарстандагы Яр Чаллы шәһәренең художество фондында эшли, балалар бакчаларын, җәмәгать оешмалары биналарын бизәү белән шөгыльләнә.

1983 елда Туймазы шәһәренә күчеп кайта һәм 1990 елга кадәр «Туймазы фарфоры» заводында рәссам-бизәүче булып эшли, Декор һәм шелкография техникасын кулланып, сувенирлар ясый. Шулай ук Туймазының «Медицина пыяласы» заводында төрле сувенирлар, вазалар ясау өчен формалар уйлап чыгара, киндердә 50гә якын рәсем-картинасын эшли.

1997 елда Туймазы шәһәрендә үзе ясаган рәсемнәр белән бизәлгән «Җир һәм күк» исемле китабы басылып чыга. Хәмит Латыйф инициативасы белән 1999 елда Туймазы шәһәренең 49 нчы номерлы училищесында «Агачтан уеп эшләү остасы» бүлеге ачыла, һәм үзе шунда укытучы булып эшли. 2000 елның май аеннан 2002 елның мартына кадәр Казан шәһәренең «Туран» оешмасында эшли. Төрле сувенирлар, җиһазларны уеп бизәкләп

эшкәртү белән шөгыльләнә. 2002-2003 елларда Саба районы Шәмәрдән бистәсенең музыка-рәсем сәнгате мәктәбендә рәсем укытучысы булып эшли. Хәзерге вакытта рәссам-шагыйрь Хәмит Латыйф Башкортстанның Туймазы шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

**Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәров** – рәссам, график, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, Үзбәкстанның һәм Татарстанның халык рәссамы.Чыңгыз Әхмәров 1912 елның 12 маенда Ырынбур губернасының Троицк шәһәрендә туа. Шәһәрдәге мәктәпне тәмамлагач, Чыңгыз 1927-1930 елларда Пермь сәнгать техникумында укый. 1930-1935 елларда Чыңгыз Әхмәров Сәмәрканд шәһәрендә яши. 1935 елда ул В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтына укырга керә, сугыш башлану сәбәпле, аны 1942 елда Сәмәркандта тәмамлый. Чыңгыз Әхмәров 1955-56 елларда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры фойесын һәм диварларын (“Бию”, “Музыка”, “Сәнгать” композицияләре), 1957 елда Казан елга порты фасадын мозаикалар белән бизи. «Татар хатыны» (1968), «Йосыф һәм Зөләйха» (1975) картиналарын яза. 1980 елларда рәссам татар тарихы һәм мәдәнияте темасына әйләнеп кайта. Шушы елларны Чыңгыз Әхмәров «Мәрҗани Үзәк Азиядә», «Сөембикә Үтәмеш Гәрәй белән», «Габдулла Тукай», «Тормыш», «Татар кызы», «Татар биюе» дигән хезмәтләрен иҗат итә.

Чыңгыз Әхмәров – Үзбәкстанда монументаль сәнгатькә нигез салучы. Ул 1944-47 елларда, архитектура академигы А.В.Щусев белән берлектә, А.Нәваи исемендәге Ташкент опера һәм балет театры диварларын бизи; 1953тә Мәскәү метросының «Киевская-боҗралы» станциясе өчен мозаика паннолары һәм фрескалар эшләүдә катнаша. Рәссам Ташкент, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләрендәге байтак биналарга ямь өстәп торган монументаль хезмәтләре белән дә яхшы мәгълүм.

Чыңгыз Әхмәров 1995 елның 13 мартында Ташкент шәһәрендә вафат була.

**Монументаль-бизәлеш сәнгате**

Монументаль-бизәлеш сәнгате, бизәлеш сәнгате өлкәсе; биналарны, скульптура-парк ансамбльләрен, фонтаннарны һ.б.ны бизәү өчен архитектур-фәза мохитында иҗат ителгән әсәрләр. Монументаль-бизәлеш сәнгате архитектур һәм скульптур декор (әвәләп ясау, уеп бизәкләү һ.б.), дивар бизәге, мозаика, витраж, гобелен һ.б. керә. Татарстан территориясендә сакланып калган элгәреге монументаль-бизәлеш сәнгате әсәрләрен 13–14 йөз Болгар шәһәре архитектурасы истәлекләрендә, Казан Кремлендәге таш корылмаларның архитектур фрагментларында күрергә мөмкин. 16 йөз уртасыннан башлап, рус монументаль-бизәлеш сәнгатенең төзелүче биналарның **экстерьерларын** һәм **интерьерларын** бизәүдә кулланылган таш рельефка уеп бизәк төшерү, диварны **фреска** белән бизәкләү, керәч белән тышлау (пыяласыман ялтыравыклы чынаяк кирпеч белән бизәлеш кирпечен аралаштырып өю), агачны уеп бизәкләү һ.б. төрләре үсеш ала. Таштан салынган татар мәчетләре (Казандагы Мәрҗани мәчете, Апанаев мәчете, Зәңгәр мәчет; Кышкар мәчете һ.б.) бизәлешендә (ташка уеп бизәк төшерү, гипс белән тышлау, чынаяк кирпеч белән тышланган декор) Европа стильләре йогынтысы сизелә.

Монументаль-бизәлеш сәнгатенең аеруча зур үсеш чоры 1970 еллар ахыры – 1980 еллар уртасына туры килә. Яңа шәһәрләрдә – Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт, Лениногорск, Яшел Үзән һ.б.да – Монументаль-бизәлеш сәнгате әсәрләре типлаштырылган проектлар буенча төзелгән җәмәгать биналарына сәнгатьлелек һәм үзенчәлек биреп торалар. Аерым бер төркем материалларны һәм башкару техникаларын файдалануда гомуми үсеш юнәлешләре дә билгеләнә. Мәктәпләрне бизәүдә – керәч мозаика, гипска уеп бизәк төшерү, дивар бизәге; балалар бакчаларында – майолика, мозаика, агачка уеп бизәк төшерү, эре мәдәният объектларында монументаль-бизәлеш сәнгатенең барлык төп төрләре синтезы популяр була. Әсәрләрнең образлы телендә, чит илләрдәге алдынгы тәҗрибәне үзләштерү белән бергә, милли сәнгать традицияләрен үстерү, камилләштерүгә бәйле стильле яңа үсеш юнәлешләре барлыкка килә.

## ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ӨЧЕН ТЕКСТЛАР

**ГРАФИКА** – один из видов изобразительного искусства, близкий живописи со стороны содержания и формы, но имеющий свои собственные конкретные задачи и художественные возможности. В отличие от живописи, основным изобразительным средством графики является однотонный рисунок (т.е. световая линия, светотень): роль цвета в ней остается сравнительно ограниченной. Со стороны технических средств графика включает в себя рисунок в собственном смысле слова – во всех его разновидностях. Как правило, произведения графики исполняют на бумаге, изредка применяются и другие материалы (например, шелк или пергамент). В зависимости от назначения и содержания, графика подразделяется на станковую, которая охватывает произведения самостоятельного значения, не требующие для раскрытия своего содержания связи с литературным текстом; книжную и журнально-газетную. Рисунки, сделанные карандашом, тушью или углём – всё это графика.

**ПСИХО-ДИЗАЙН** – это наука адаптации интерьеров, архитектурных и ландшафтных а также графических стиленесущих форм под конкретного человека, его психологические особенности и потребности. Интерьер способен стимулировать и разрушать, настраивать на успех, покой или активность, снимать или усугублять внутренние проблемы человека, семьи, коллектива; активизировать творческий процесс, влиять на продажи. Создать индивидуальную дизайн-модель «под человека» можно только на основе объективной, научно обоснованной информации и методики, объединяющей принципы дизайна и психологии.

**РИСУНОК** – разновидность художественной графики, основанная на технических средствах и возможностях рисования. В отличие от живописи, рисунок исполняется твердым красящим веществом (карандаш, сангина, уголь и пр.) или пером, кистью с использованием туши, акварели. Выразительными средствами рисунка являются, как правило, штрих, пятно, линия. Такой рисунок может быть как беглой зарисовкой с натуры, так и завершенной графической композицией, включая в оригинале иллюстрацию, карикатуру, плакат. Рисунок – один из самых древних видов изобразительного искусства. В древние времена, когда ещё не было письменности, наши предки с помощью рисунка передавали свое отношение к окружающему миру. До сих пор археологи находят в пещерах, где жили когда-то первобытные люди, изображения животных.

**ПАЛИТРА** – это тонкая деревянная дощечка прямоугольной или овальной формы с отверстием. Палитра нужна художникам для работы масляными красками. Художник держит палитру в левой руке, вставив в отверстие большой палец. По краю палитры он выдавливает из тюбиков краски, а в середине палитры смешивает краски, добиваясь нужного цвета. У каждого художника есть свои любимые цвета. Одним нравятся писать картины, не используя много разных красок. А другие предпочитают разнообразие и яркость цветов в своих работах. В первом случае про художника говорят, что у него «сдержанная палитра». А во втором – «богатая, яркая палитра». То есть палитрой ещё называют и краски, которые художник и дизайнер использует в своей работе.

**АРТ-ДИЗАЙН** – одна из изящных линий развития современного дизайна. Основным качеством, которым будут обладать дизайнерские решения этого направления – это сильная художественная составляющая, основанная на принципах чистого (высокого) искусства.

Термин арт-дизайн возник в 80-е годы 20 века в Италии, с появлением там двух дизайнерских групп – «Алхимия» (А.Мендини, А.Гуэррьеро) и «Мемфис» (Э.Соттсасс), которые

бросили вызов ортодоксальному миру дизайна. Сегодня, про них бы сказали, что они запатентовали отличную креативную идею. Художественные находки, в разработках этих дизайнеров, а изначально они занимались дизайном мебели и интерьеров, стали преобладать над поднадоевшей прагматикой общеупотребимых дизайн продуктов. Отличительными чертами этого направления стали: неожиданные комбинации цвета и света; использование разностилья; смешение стилей в одном объекте; применение экзотических стилей, ранее в дизайне не применявшихся; также использование нестандартных образов и материалов, высокое качество композиции; художественная деталировка формы, качества поверхности, общего колорита; преобладание принципа hand made (сделано вручную) при создании объекта дизайна.

Арт-дизайн неразрывно связан с концептуальным искусством. Художники-концептуалисты (Арнатт, Лонг, Диббетс и др.) ставили во главу угла идеи, которые заложены в произведении искусства. Своими произведениями они выражали протест против коммерциализации искусства.

Сегодня, арт- дизайн распространен во многих сферах, связанных с дизайном предметов и окружающей среды: от интерьеров ночных баров и квартир, до арт-дизайна собственного тела (body-art),включающего дизайн кожи, ногтей, причесок. Арт-дизайн широко применяется при создании разных видов полиграфии.

Таким образом, при арт-дизайне художественные и эмоционально-образные достоинства созданного объекта будут преобладать над традициями классического дизайна, такими как рациональность или технологичность, но при этом естественно, функциональность будет обязательно присутствовать, пусть и не на основных позициях.

**ДИЗАЙН.** Определение дизайна, принятое в 1964 году международным семинаром по дизайнерскому образованию в Брюгге: «Дизайн это творческая деятельность, целью которой является определение формальных качеств промышленных изделий. Эти качества включают и внешние черты изделия, но главным образом те структурные и функциональные взаимосвязи, которые превращают изделие в единое целое как с точки зрения потребителя, так и с точки зрения изготовителя». Дизайн упаковки – процесс проектирования, или оформления упаковки продукта в соответствии с утвержденными визуальными константами торговой марки бренда, к которому относится продукт. В широком смысле – самостоятельная художественная дисциплина со своими законами, историей и канонами. Стайлинг дизайн – удожественная адаптация уже готовой формы (интерьер-экстерьер) или улучшение технической части объекта. В России развивается довольно причудливо средовой дизайн – дизайн архитектурной среды (интерьер-экстерьер), услуги дизайнеров, проектирующих художественные праздники, выставки и тд.

**КАЛЛИГРАФИЯ** (от греч. – «красивый почерк») – одна из отраслей изобразительного искусства. Каллиграфию так же не редко называют **искусством красивого письма**. История искусства каллиграфии связана с историей создания рукописного шрифта и инструментами для письма. До изобретения книгопечатания каллиграфия была основным способом графического оформления текста.

Письменность зародилась примерно 5000 лет назад. В этот период память людей стала ослабевать и возникла необходимость записывать информацию. Примерно тогда же возникла и каллиграфия. Ее стили и начертания меняются под влиянием времени. Она находится в состоянии постоянной эволюции, и каждый раз принимает стили той эпохи, в которой существует. Особое отношение к каллиграфии наблюдалось на востоке. В качестве инструментов написания использовались кисть или перо, чернила.

Основные направления развития каллиграфии это: Западно-Европейская каллиграфия и Восточно-Азиатская. В Китае, Японии и мусульманских (арабских) странах каллиграфия появилась раньше, чем в западно-европейских и достигла статуса одного из видов изящных искусств, равного живописи и поэзии.

Из стремления соединить стиль начертания слов с их смыслом возникли и существовали на протяжении многих столетий четко отработанные и освященные традицией приемы графической стилистики. Их предназначение – усиливать эмоциональное воздействие на читателя продуманным соответствием каллиграфического почерка смысловому и литературно-стилевому содержанию написанного текста. Существо же заключалось в том, что произведения определённого литературного стиля или научного содержания записывались определённым каллиграфическим почерком.

Арабская каллиграфия возникла на базе копирования Корана, который считается творением Аллаха, поэтому написанное слово само по себе получило сакральный смысл. Многие религии используют изображения (иконы) для выражения основ своих убеждений, ислам же вместо этого предлагает каллиграфию. Отказ от изображений, как от возможной формы идолопоклонства, привел к развитию каллиграфии в религиозном направлении. Искусство письма всегда занимало необычайно высокое место в арабской, а затем и в исламской культуре.

**ЖАНР.** В изобразительном искусстве: понятие, характеризующее область искусства, ограниченную определенным кругом тем. Различают, в основном, жанр исторический, бытовой, батальный; жанр портрета, пейзажа, натюрморта. Понятие жанра сложилось в XV – XVI вв.: разделение искусства на отдельные жанры способствовало более глубокому изучению и отражению в искусстве действительности, а также выработке и развитию необходимых для этого средств. Современное понятие жанра оказывается особенно развитым на почве станковой живописи. В скульптуре подразделения на жанр почти не существует, т.к. здесь в основу классификации кладется

скорее целевое назначение скульптурного произведения, чем тематический принцип. Но и тут сохраняется все же устойчивый тематический жанр портрета.

**ИНТЕРЬЕР** – французское слово, оно означает «внутренний». Интерьером называют оформление внутри разных помещений – жилых комнат, дворцов, общественных зданий. Кроме этого интерьером называют изображение комнаты, украшенное (оформленное) мебелью, коврами, шторами и другими вещами. Художники, пишущие интерьер, очень тщательно изображают все подробности обстановки – мебели, ковров, светильников. Глядя на картину мы можем представить себе, как жили люди – современники художника. Кроме того, интерьер может многое рассказать и о характере этих людей.

**КОНСТРУКТИВИЗМ,** направление в изобразительном искусстве, архитектуре и дизайне 20 в., поставившее своей целью художественное освоение возможностей современного научно-технического прогресса. В зодчестве тесно примыкает к рационализму и функционализму. Сложилось в 1910-е гг., прежде всего на базе кубизма и футуризма, разделившись вскоре на два обособленных потока: «конструктивизм социальный», тесно связанный с задачами «социальной инженерии», создания нового человека путем радикального преобразования окружающей его предметно-материальной среды. Ярчайшими представителями конструктивизма в графическом дизайне были В. Маяковский и В. Родченко.

**ЛИТОГРАФИЯ** – широко распространенная разновидность графической техники, связанная с работой на камне (плотный известняк) или заменяющей его металлической пластине (цинк, алюминий). Литография исполняется художником на поверхности камня жирным литографским карандашом и специальной тушью. Вслед за травлением камня кислотой рисунок смывают; взамен наносится типографская краска. Ее накатывают валиком по увлажненному камню. Печатание производят на специальном станке.

**ПИКТОГРАММА** – стилизованное и легко узнаваемое графическое изображение, упрощенное с целью облегчения визуального восприятия. Ее цель заключается в усилении характерных черт изображаемого предмета. Схема проста: увидел – узнал – понял. Увидел потому, что она привлекла внимание; узнал то, что изображено на ней; понял, что же именно она хочет тебе сообщить. Пиктограмма (лат., «pictus» – нарисованный) – изображение, используемое в качестве символа в ранних системах письменности. Например, полумесяц используется как обозначения луны, волнистые линии – в качестве обозначения воды. Обычно это знак, соответствующий какому-либо объекту; используется с целью предоставления более конкретной информации, подчеркивающей его типичные черты. Отсюда, пиктографическая форма письма -письменность, использующая пиктограммы, искусство записи событий или выражения идей рисунками, а также изображение статистических данных и соотношений графиками, диаграммами, символами и подобными способами.

**ПОСТЕР**, или более привычное для нас – плакат – крупноформатное, изображение, сделанное в рекламных, агитационных, информационных или просветительских целях. В теории графического дизайна – постер это сведенное в четкую визуальную формулу рекламное сообщение, предназначенное для побуждения получателя сообщения на конкретные действия. С точки зрения особенностей плаката, как рекламоносителя, он может выступать в виде рекламной полосы в печатном издании, уличного лайтбокса, придорожного щита (биллборда) или просто афиши. С содержательной точки зрения, плакат должен соединять в цельную композицию ряд элементов графического дизайна, находящихся в определенной взаимосвязи друг с другом, а именно: крупное, рисованное или фотографическое изображение, слоган, расшифровывающий рекламное сообщение и элементы фирменного стиля рекламодателя (знак и логотип).

**ФАКТУРА** (от лат factura – деление). В живописи, скульптуре и дизайне: материальные, осязаемые свойства поверхности художественного произведения, использованные как средство правдивого изображения действительности. Фактурные различия определяются, прежде всего, особенностями самой натуры: в живописи, например, прозрачные, глубокие тени обычно передаются тонким и ровным красочным слоем в противоположность густому, рельефному письму ярко освещенных мест и бликов. В скульптуре лицо человека, по сравнению с его одеждой или волосами, исполняется более гладко и т.д. Свойства фактуры зависят также от технических возможностей материала, от характера задания (набросок, например, никогда не пишут как картину); от масштабов изображения, от индивидуальных особенностей художника.

## ПРО КРАСОТУ И СЛОЖНОСТЬ ЧЕРНОГО И БЕЛЫХ ЦВЕТОВ

При украшении общественных мест дизайнеры с большим удовольствием применяют черный цвет. Потому что он дает им возможность не применяя особых усилий и фантазии разработать дизайн со вкусом. Ведь роскошный черный цвет придает ему оттенок богатства. В интерьере дома черный следует применять продуманно, как ни говори, считается, что он навеевает печаль и “давит”. Специалисты считают, что черный в комнате должен занимать лишь какую-то часть. Черные стены ли, черные полы ли, черный потолок ли – только что-то одно. Черная стена и белая либо цветная мебель, в светлых цветах аксессуары и ткани придаст комнате незабываемый оттенок. Черный пол поднимет “авторитет” комнаты. А вот черный потолок, не говорите, что давит, если он блестит как зеркало, то высота комнаты как минимум в два раза будет казаться больше. Если не хватает смелости для черного дивана, пола или потолка, то черный можно применить в одном или нескольких других предметах мебели. Это придаст благородство интерьеру.

Черный цвет можно применять во всех интерьерах. Холл, гостинная, рабочий кабинет, кухня, ванная, спальня... только в детской комнате специалисты советуют не применять черный цвет. Но когда ребенок достигает подросткового возраста, этот цвет может показаться выигрышным!

Леонардо да Винчи называет белый цвет “первым из основных цветов”. Говоря о дизайне, то в 20-30-х годах прошлого столетия в США белый считался модным в дизайне интерьера. Это говорило о богатстве и вкусе хозяев дома. Белые стены, белая мебель на полу белый ковер и открытых цветов украшенные маленькие подушки, памятная мелочовка, картины – расширят комнату и придадут роскошный вид. С остальными цвета добиться такого будет сложнее.

Таким образом, украшение комнат, примененные в их дизайне основные цвета определяют атмосферу дома. Будь то торжественный или поднимающий настроение, или успокаивающий – это все связано с цветом.

## ЖИВОПИСЬ КАЗАНСКИХ ТАТАР

Живопись, как самостоятельная область искусства, у казанских татар совершенно не существует, если не считать несколько казанских миниатюристов и калиграфов, работавших до средины XIX века.

Если искусство казанских татар за последние века мало себя проявило в области зодчества, живописи и скульптуры, то в области бытового народного творчества оно дало много интересного и оригинального. Правда, в их современном быте чувствуется некоторое смешение вкусов, сложившихся, с одной стороны, под влиянием Востока и ислама, и с другой, под тем непосредственным впечатлением городской моды и культуры, которые за последнее время стали все чаще и чаще проникать в народную жизнь. Увлечение татар своим бытом и народным творчеством объясняется тем, что после порабощения этого народа в XVI веке, он не имел возможности открыто творить свое большое национальное искусство, и ему пришлось замуроваться в своей домашней обстановке, концентрируя духовные свои потребности и художественные стремления исключительно в интимной обстановке своего семейного очага. И отсюда

декоративность уюта, интимная красота убранства их жилищ составляет одну из специфических сторон творчества народной фантазии татар.

При посещении целого ряда татарских домов нам пришлось наблюдать такое же устройство «черной избы», как это описывает историк конца XVIII века. Здесь все по старинному, патриархальному, даже расположение предметов у них имеет свое традиционное место. С правой стороны от входа всегда бывает большая печь, своеобразного вида, с низким шестком и двумя нотами для варки пищи. Против печи, у передней стены нары, покрытые войлоком и стеганным «курпе», тут же, на нарах «тюшэк», подушки, перины и вверху кашага с двумя занавесками. За печью в углу устраивается всегда небольшая коморка, на которой стоит громадных размеров медный таз и несколько ковшов с водой для омовения. Общая нарядность «черной избы» всегда бывает довольно убога, но все же в ней непременными элементами обстановки должны быть: шкафчик с посудой, зеркало, часы, сундуки, покрытые пестрыми тканями и на окнах цветы. Совсем другое впечатление производит «белая гостевая комната». Она вся в коврах, занавесках, столы покрыты богатыми рисунчатыми скатертями, постель нарядно убрана одеялом (курама) и подушками до 10 штук разных размеров, кровать уютно задрапирована пологом (чаршау). Окна все уставлены банками с любимыми цветами – геранью и бальзаминами. В простенках обязательно расставлены шкафчики с фарфором, е безделушками, зеркала, горки и старинного фасона часы с боем. На почетном место прибиты в рамах остекленные священные шамайли разнообразных видов и восточных шрифтов.

На этом довольно красочном фоне, особенно эффектно выделяются персонажи интерьеров, разряженные в свои национальные костюмы. Первое место в смысле нарядов, конечно, прежде всего, принадлежит женщине. Хотя она и далека бывает от общества, ведя замкнутую жизнь, но все же татарки большие любительницы красиво одеться. И взгляд на костюм женщины, в житейской обстановке у татар сложился, и как на что-то важное, имеющее большое значение для жизни.

## СӘНГАТЬЛЕ ИТЕП СӨЙЛӘҮ ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

### Туган телем

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел – вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә.
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле – ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне (Р.Миңнуллин).

### Тел

“Тел, тел”, - дибез, тел нәрсә!
Әгәр телә белмәсә:
Бәгырьләрне телә-телә
Усал көлә белмәсә,
Йомшарып, тасма телләнеп
Җанга керә белмәсә?!
Телнең ачысы була,
Телнең төчесе була:
Ачысын да, төчесен дә
Татыр кешесе була.
Ачы тел – хак агайда,
Төче тел – ялагайда:

Төче тел бик кирәк була
Тәлинкә ялаганда.
Телнең тияге булмый,
Телнең сөяге булмый.
Никадәрле сөйләсә дә
Телнең сөяле булмый.
Эшләгәннең кулында,
Сөйләгәннең – телендә.
Телнең серен белим дисәң –
Хикмәт телнең төбендә.
Тел шигырьләр дә укый,
Тел вәгазьләр дә тукый,
Өнди ул әдәпкә дә,
Күндәм ул әләккә дә.
Ләчтит саткан да шул тел,
Дан тараткан да шул тел,
Тәнкыйтьченең авызында
Эшсез яткан да шул тел.
Тел елата, юата,
Матур уйлар уйлата,
Йә үрти, йә көлдерә,
Үңдыра йә бөлдерә.
Сөйдергән дә тел генә,
Көйдергән дә тел генә...
Тел шикелле универсал
Бу дөньяда бер генә.
Телең барында бер дә
Сүз әйталмый тилмермә:
“Телем – дошманым!”– дип әйтеп,
Телгә телең тидермә.
Уе юкның – теле юк,
Теле юкның – иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк (Н.Арсланов).

## Туган тел турында бер шигырь

И, кардәшем! Бер хаҗәтсез кайчак
Телне шундый бозып сөйлисең
Ил колагын хурлап, халыкның
Рухын рәнҗетәмен димисең!

Мескенләнмә, бакый гомер килгән
Тел байлыгын итмә кадерсез.
Бер уйласаң, илаһи бит, изге
Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз!

Һич мәртәбә түгел телдә
Җиң очына карап сөйләшү.
Көчле, горур сөйләш! Кирәк икән,
Хаким телләр торсын көнләшеп!

Иренмә син, туган, туган телнең
Асыл байлыкларын ачарга.
Без ваемсыз булсак, чит-ят сүзләр
Хәзинәңне әзер басарга!

Ана телен ватып-бозып сөйләп,
Кешелегең генә төшә бит;
Корама тел, яман чир булып,
Яңа буыннарга күчә бит!

Күп телләрне белү- яхшы шөгыль,
Туган телең үги калмаса;
Җаның салып әйткән әткәң сүзен
Синең аша балаң аңласа.

Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
Матур итеп татар телендә! (Р.Фәйзуллин).

### Ике канат

Туган телем күпеллардан бирле
Чәчәк ата йөрәк түремдә.
“Әнкәй” дигән иң беренче сүзне
Мин әйткәнмен татар телендә.

Гашыйк булган сымак юлда егет
Җилдән җитез чапкан атына;
Мин гашыйкмын сиңа, туган телем,
Син чын байлык минем зәүкыма.

Газиз телем гасыр диңгезләрен
Кичә-кичә килгән еракτан.
Шушы телдә бәхет теләп илгә,
Җырларымны миргә яңратам.

Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый.
Туган телен яратмаган кеше
Башкаларның телен яратмый.

Заман миңа:“Югарыга мен!” – дип
Ике канат биреп үстерде.
Канатымның берсе – татар теле,
Икенчесе – бөек рус теле (Ә.Ерикәй).

### И туган тел

И борынгы татар теле,
Кадерле туган телем.
Син минем көчле коралым,
Син миңа – акыл, белем.

Син шигърият кояшым,
Син гасырлар ялкыны,
Тарихлар ашыкмый аккан
Син туган тел аркылы.

Син  халкымның  һич суынмас
Кодрәтле кайнар каны,
Мәңге дә сафлыгын җуймас
Сүрелмәс бәллүр җаны.

И туган тел, и матур тел –
Ватаным кебек гали.
Әнием кебек кадерле,
Тормышым кебек гади (Р.Рәкыйпов).

**Туган тел**
И минем җандай кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.

Тик синең ярдәм белән мин,
Тик синең сүзләр белән
Уйларын йөрәккәемнең
Дөньяга әйтә беләм (Х.Туфан).

**Туган тел хакында**

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: “Әти!” – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әти!” – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр! (Зөлфәт).

## УКЫП ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН
## МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР

Һәр халыкның гаҗәп дәрәҗәдә бай хәзинәсе – ул халык авыз иҗаты әсәрләре. Татар халкының тормышын зур тарихи вакыйгалардан һәм дан казанган батырлардан, дастан, әкият, бәет, мәкаль-әйтем һәм җыр-биюләрдән, иҗтимагый бәйрәмнәрдән һәм милли йолалардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Аларда халыкның әхлакый идеаллары, хезмәт сөючәнлеге, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә булган чиксез мәхәббәте, дөреслек, сафлык кебек сыйфатлары чагылыш тапкан.

Мәкаль – тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләрне гомумиләштереп, тапкыр әйтелгән тәгъбир. Мәкаль ул – тормышның һәртөрле җил-давыллары эчендә безне аталарча кайгырткан киңәшчебез. Мәкаль әйткәндә син халкыңнан тел генә алып калмыйсың, акыл-тәҗрибә, белем-хикмәт аласың. Мәкальләр – тел хәзинәсе. Аларда өйрәнелмәгән бик бай сүзлек фонды ята. Ул телчеләр, әдип-шагыйрьләр, матбугат һәм укытучылар өчен бик зур байлык чишмәсе.

Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел.
Әдәп башы – тел.
Тел күрке – сүз.
Тел дигән дәрья бар, дәрья төбендә энҗе бар,
Белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр.
Теле татлының дусы күп.
Белмәгәнне сөйләмә, кирәк булганны сөйлә.
Телләр белгән – илләр гизгән.
Телнең зиннәте – тугры сүз.
Туган телен кадерләгән халык кадерле булган.
Тел барлыгы бай итәр – тел юклыгы юк итәр.
Тел белән әйтмичә, бармак белән төртеп булмый.

Теле барлар халык булган, теле юклар балык булган.
Карак карак белән караңгыда табыша.
Ашына күрә табагы, эшенә күрә тамагы.
Икмәк йөрми корсак артыннан,
Корсак йөри икмәк артыннан.
Имгәксез җиләктә ләззәт юк.
Чыпчык котырса, ябалакка сикерер.
Чикләвек ватмасаң, төшен ашый алмассың.
Уңганның кулы туңмас, суыкка тәне туңмас
Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
Киң сөйләгән кичкә җитмәс,
Киң атлаган ишеккә җитмәс.
Эшкә булса – уф табаным,
Ашка булса – китер табагым.
Ялгыз булып ни кырдың?
Күмәк булсаң, өй кордың.
Ярык кайда – җил шунда,
Ялкау кайда – сүз шунда.
Сәләтсез сәнәк сындырыр,
Көчсез көрәк сындырыр.
Сыныкка сылтау, җимереккә терәү.
Тишек чиләктә су тормас, тишек авызда сүз тормас.
Янчыгыңны нык яшерсәң,
Каракка эшең төшмәс.
Тышка карап хөкем итмә, эчкә карап хөкем ит.
Яманга барма, яхшыдан калма;
Икмәге юк – ач, ялкау кеше ялангач.
Кояшның кадере баегач сизелә.
Киң сөйләгән кичкә җитмәс,
Киң атлаган ишеккә җитмәс.
Озын янында кыска  беленер.
Игеннең җаен иккән белер,
Арбаның җаен җиккән белер.
Йоклаган – көлке. алыр,
Йокламаган – төлке алыр.
Болганчык суда балык тотасы җиңел.
Үзең карлыгач булгач,
Балаң сандугач булмас.

## КОНТРОЛЬ ЭШ БИРЕМНӘРЕ

(1)Татар халкы элек-электән бик зәвыклы халык булган. (2)Бу турыда бүгенге көнгә кадәр сакланып калган зәркән эшләнмәләр сөйли. (3)Аларны ирләр дә, хатын-кызлар да кулланган. (4)Ирләр кыйммәтле кашлы йөзекләр, билбау прәшкәләре тагып йөрсәләр, хатын-кызларның бизәнү әйберләре күпкә баерак, төрлерәк һәм зәвыклырак булган. (5)Алар арасында татар сыргасы, күкрәкчә, яка чылбыры, беләзекләр, йөзекләр татар хатын-кызы милли киеменең төп атрибутлары саналганнар.

(6)Зәркән эше - татарларда бик үзенчәлекле кәсепләрнең берсе, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгәне. (7)Ул борынгы сәнгать төрләренең берсе санала.

(8)Ташларның матурлыгы кешелекне күптәннән җәлеп итә. (9)Татар халкы да ювелир эшләнмәләрен үз итә. (10)Ювелир эшләнмәләр халык тормышының образлы елъязмасы саналырга хаклы. (11)Алар форма, орнамент, техника һәм төс ярдәмендә халыкның килеп чыгышын, этник процессларны, башка халыклар белән мәдәни-тарихи багланышларны, халыкның көнкүреш һәм иҗтимагый шартларын ачып бирәләр. (12)Идел буе татарларыннан башлангыч алган ювелир сәнгатендә төп эш материалы көмеш була. (13)Болгарлар фин-угор халыклары белән аралашып яшәгәнгә күрә, ювелир эшләнмәләрендә дә форма ягыннан, тәңкәләр һәм коралллар белән бизәлеше ягыннан охшашлыклар шактый. (14)Әлбәттә, бу өлкәдә көнчыгыш һәм рус йогынтысы да булмый калмый. (15)Славян, бигрәк тә рус халкы тәэсире XVI-XVII гасырларда бигрәк тә көчле булган, татар зәркән эшләнмәләренең формалары русныкына охшау шуннан килә. (16)Шулай да татар зәркән эшенә көнчыгыш тәэсире шактый сизелерлек була.

**Хаталы** билгеләмәне табыгыз.
1) *йогынтысы* сүзендә икенче иҗектә килгән [ы] авазы [о]лашып әйтелә.
2) *ташларның* сүзендә авазлар һәм хәрефләр саны бертигез.
3) *сәнгать* сүзендә әйтелеш белән язылыш аерыла.
4) *Орнамент* сүзендә кулланылган сузыклар калынлыкта ярашалар.

**Саңгырау** тартык авазлар гына кергән сүзне табыгыз.
1) *тәңкә*
2) *кәсеп*
3) *көмеш*
4) *халык*

**Хаталы** сүзтезмәне табыгыз.
1) *рус халыкы*
2) *зәркән эше*
3) *борынгы сәнгать*
4) *халык тормышы*

***Тәэсир*** сүзендә *ь хәрефе* ни өчен язылган?
1) һәмзә тартыгын белдерә
2) иҗекне нечкәртә
3) тартыкны нечкәртә
4) аеру билгесе булып тора

**Кушма булмаган сүз**не билгеләгез.
1) *кашлы йөзек*
2) *беләзек*
3) *яка чылбыры*
4) *хатын-кыз*

**Елъязма** сүзенең төрен билгеләгез.
1) *гади сүз.*
2) *парлы сүз.*
3) *саф кушма сүз.*
4) *тезмә сүз.*

**Тамыр һәм сүзьясагыч** кушымчадан гына торган сүзне билгеләгез.

1) *көнкүреш*
2) *тормыш*
3) *билбау*
4) *охшашлык*

**Күтәрелмә ялган дифтонглы** сүзне билгеләгез..

1) *иҗтимагый*
2) *әйберләр*
3) *зәвыклы*
4) *шулай*

**Борынгы** сүзендәге аваз үзгәрешен билгеләгез.

1) *борын ассимиляциясе;*
2) *акустик ассимиляция;*
3) *кече тел ассимиляциясе;*
4) *ирен ассимиляциясе.*

**Хатын-кызлар** сүзендә басым төшкән иҗек санын билгеләгез.

1) *беренче*
2) *икенче*
3) *өченче*
4) *дүртенче*

10 нчы җөмләдән сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчү ысулы белән ясалган **кушма сүзне** табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

12 нче җөмләдән **ирен гармониясенә** мисал табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

13 нче җөмләдән **кушма сүзне** табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

7 нче җөмләдә **морфологик принцип** белән язылган сүзне табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

10 нчы җөмләдәге сүзләрдән **ясагыч кушымчалы** сүзләрне табып языгыз.
Җавап: ______________________________.

Тексттан **3 парлы** сүзне табып языгыз
Җавап: ______________________________.
Тексттан **ирен гармониясенә 7** мисал табып языгыз .
Җавап: ______________________________.
13 нче җөмләдәге сүзләрнең синонимнарын кулланып, үзгәртеп языгыз.
Җавап: ____________________________________________________.
4 нче җөмләдәге кайбер сүзләрнең антонимнарын табып, парлап языгыз.
Җавап: ____________________________________________________.
Тексттагы сүзләр кергән өч мәкаль яки өч фразеологизм языгыз.

Җавап: ____________________________________________________.

## РЕФЕРАТ ТЕМАЛАРЫ

1. Татар халкында сынлы сәнгать төрләре.
2. Татар халкының гамәли-бизәлеш сәнгате.
3. Татар халкының рәсем сәнгате.
4. Татар халкының зәркән сәнгате.
5. Татар халкының күн сәнгате.
6. Татар халкының чигү сәнгате.
7. Татар халкының керәч сәнгате.
8. Татар халкының гобелен сәнгате.
9. Татар халкының тукучылык сәнгате.
10. Татар язуы тарихы.
11. Татарларда язу сәнгате. Танылган каллиграфлар.
12. Татар халкының сүз сәнгате.
13. Татар халкының милли киемнәре.
14. Күренекле татар рәссамнары.
15. Күренекле татар сынчылары.
16. Казанда татар шәхесләренә куелган һәйкәлләр.
17. Татар халкының театр сәнгате тарихы.
18. Татар халкының музыка сәнгате тарихы.
19. Татар халык авыз иҗаты.
20. Татар сәнгатен өйрәнүче сәнгать белгечләре.

....

# СӘНГАТЬ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕКЧӘСЕ

**АВТОТИПИЯ –** тонлы цинкография, репродукциянең иң киң таралган төрләреннән берсе, югары басма чаралары (фотография, төсле рәсем, акварель).

**АКАДЕМИЗМ –** сәнгатьнең тасвири сәнгать академияләре нигезендә үсеп чыккан юнәлеше.

**АМПИР –** XIX гасырның беренче чирегендә Европа илләрендә барлыкка килгән архитектура, гамәли бизәлеш һәм тасвири сәнгать стиле(өслүбе).

**АНИМАЛИСТ** – хайваннар рәсемен яки сынын ясаучы рәссам яки сынчы.

**АНСАМБЛЬ** – тасвири(сынлы) сәнгатьтә бербөтеннең төрле кисәкләре арасында үзара ярашканлык, берләшкәнлек.

**АНТИК СӘНГАТЬ –** антик чор сәнгате; Борынгы Греция һәм шулай ук мәдәни традиция тәэсирендә үсеш алган дөнья илләре һәм халыклары сәнгате.

**АНТИКВАР** – борынгы әйберләр белән сәүдә итүче; борынгы әйберләр һәвәскәре.

**АНФАС** – йөзнең алгы яктан төшерелгән сурәте.

**АППРОШ** – типографиядә җыелган хәрефләр яки сүзләр арасында буш ара.

**АПСИДА** – планында ярымтүгәрәк, турыпочмаклы яки кырлап ясалган ярымгөмбәз яки гөмбәз белән ябылган бинаның чыгып тора торган өлеше.

**АРАБЕСКА –** Европа сәнгате мөселман сәнгате өлгеләре тәэсирендә таралган геометрик фигуралардан һәм яфрак, чәчәк һ.б.ш. бизәкләрдән торган катлаулы орнамент төре.

**АРХИТЕКТУРА** – **МИГЪМАРЛЫК** (мигъмарият) – материаль мохитны барлыкка китерү өчен сәнгатьчә оештырылган биналар, башка корылмалар һәм аларның комплекслары.

**А СЕККО –** кипкән штукатурка өстенә диварга рәсем ясау техникасы төрләреннән берсе.

**АТРИБУЦИЯ** – аноним әсәрләрнең конкрет бер авторга, милли яки җирле сәнгать мәктәбенә караганлыгын ачыклау, иҗат ителгән вакытын билгеләү.

**АФФРЕСКО – АЛЬ ФРЕСКО** – диварга рәсем ясауның техник бер төре – кибет бетмәгән известьле штукатурка өстенә рәсем төшерү.

**АЭРОГРАФ –** кәгазь, тукыма, керамика өстенә буяуны кысылган һава белән бөркеп төшерергә ярдәм итә торган әсбап.

**АЭРОГРАФИЯ** – аэрография яки трафарет белән ясалган рәсем техникасы.

**БАГЕТ** – картина, портрет кысалары һәм кәрнизләр ясау өчен кулланыла торган бизәкле юка тар агач такта.

**БАЛЯСИНА – ТЕКМӘ** – баскычларның, балконнарның һ.б.ш. култыксаларын тотып тора торган агач, таш, металлдан ясалган сырлап бизәлгән тәбәнәк баганалар.

**БАРЕЛЬЕФ** – яссылык өстенә калкытып ясалган сынлы (скульптур) рәсем.

**БАРОККО –** XVI г. ахырында Италиядә барлыкка һәм Көнбатыш Европа илләрендә XVIII г. башына кадәр таралган сәнгать өслүбе.

**БАСМА** – чүкелгән бизәккә яки филиграньга охшатып ясый торган зәркән техникасы төре.

**БАСОН – УКА, УКАЛЫ ТАСМА, КӘЙТӘН –** өй җиһазларын, кием-салымны һ.б.ш. бизәү өчен махсус туку станогында үреп эшләнгән тасмалар, баулар, чуклар.

**БАТИК** – киҗе-мамык тукымаларын бизәкләү техникасы, ш.у. шушы ысул белән бизәлгән төрле күптөсле тукыма. Бу ысул, рәсемне балавыз белән төшереп, тукыманы буяуга манудан тора. Тукыманың балавыз төшмәгән урыннары гына буяла.

**БЛИК – АК ТАП –** кара фонга төшкән яктылык табы.

**БОРДЮР – КАЙМА, ӘДЕП** – бизәкле композициянең кырыен уратып алынган озынча буй.

**БУГОРЧАТАЯ ФИЛИГРАНЬ – КҮПЕРТМӘ ҖЕПКЫР** – зәркәнчелек сәнгатендә XVI-XVII гасырларда татар осталары кулланган ысул. Җепсыман нечкә алтын яки көмеш чыбыкны бөтереп-урап ясалган кабарынкы бизәк.

**БЫТОВОЙ ПОРТРЕТ – КӨНКҮРЕШ ПОРТРЕТЫ –** шәһәрнең урта катлау халкы һәм мул тормышлы крестьяннар зәвыгы таләп итә торган тасвири сәнгатьнең бер жанры.

**БЮСТ** – кеше гәүдәсенең билдән югары өлешенең сыны.
**ВАЛЁР –** рәсем сәнгатендә һәм графикада буяу төсенең аерым сыйфаты; башка төсмерләр белән чагыштырганда күпмедер дәрәҗәдә яктылыгы һәм күләгәсе булган тон төсмере.
**ВАЯТЬ** – ясарга, һәйкәл ясарга (кырып, кисеп, әвәләп, коеп).
**ВИНЬЕТКА** – китапка яки кулъязмада текстның башында яки ахырында кечкенә рәсем,
**ВИТРАЖ** – ишек, тәрәзәдәге төсле пыялалардан ясалган бизәк, рәсем.
**ГЛАЗУРОВАНИЕ** – ялтыравык йөгертү.
**ГОБЕЛЕН** – бизәкләп тукылган дивар келәме.
**ГРАВЕРЛАУ** – каты материал өстенә чокып сурәт, бизәк, язулар төшерү.
**ГРАФИКА** – сызыклар һәм штрихлар белән генә рәсем ясау сәнгате.
**ГРИЗАИЛЬ –** бер, гадәттә соры төснең төрле төсмерләре белән ясалган рәсем.
**ГУАШЬ** – үтә күренми торган акварель буяу һәм шундый буяу белән ясалган рәсем.
**ДЕКОРАТИВНОЕ ИСКУССТВО** – **БИЗӘЛЕШ СӘНГАТЕ**. Төрләре: монументаль-декоратив сәнгатькә, (архитектура бизәлеше, дивар рәсемнәре), гамәли бизәлеш сәнгате(көнкүреш нәфис эшләнмәләр), матурлау сәнгате.
**ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО – ГАМӘЛИ БИЗӘЛЕШ СӘНГАТЕ –** нәфис мәгънәсе һәм декоратив образлары булган, кешенең көнкүреш ихтыяҗларына турыдан-туры бәйле сәнгать төре.
**ДЕКОРАТОР –** 1)театрда декорацияләр ясаучы рәссам;
2) йортларны декорацияләр белән бишәүче белгеч.
**ДИЗАЙН** – предметларның сәнгатьчә эшләнешен проектлаштыру, конструкцияләү.
**ДИЗАЙНЕР** – сәнәгать җитештереп чыгара торган әйберләрне сәнгатьчә эшләнеше ягыннан проектлаштыручы рәссам-конструктор.
**ДИНАМИКА ЦВЕТА** – төснең үзгәрә баруы.
**ДИОРАМА** – 1) үтә күренмәле тукыманың яки тонык пыяланың ике ягына ясалган картина; 2) алгы планга күләмле предметлар куелып ясалган ярым түгәрәк зур картина.

**ДИПТИХ** – 1) рельефлы сурәтле яки ике өлешле складень; 2) уртак фикер белән бәйләнгән ике рәсемле композиция.
**ЖАНР** – рәсем сәнгатендә уртак темалар, сурәтләү предметлары белән берләштерелгән әсәрләр җыелмасы (тарихи жанр , көнкүреш жанры, баталия жанры, натюрморт жанры, пейзаж жанры, анималистик жанр).
**ЖИВОПИСЬ – РӘСЕМ СӘНГАТЕ -** өч сәнгать (рәсем сәнгате, графика, сынлы сәнгать) арасында традиция буенча беренчелекне алып торучы тасвири сәнгать төре.
**ЗЕРНЬ – БӨРТЕКЛӘҮ, АРПАЛАУ** – зәркән сәнгатендә ювелир техникасы, зәркән эшләнмәләренә эретеп ябыштырыла торган вак (0,4 мм диаметрлы) алтын, көмеш шарчыклар.
**ИЗОБРАЖЕНИЕ** – сурәтләү, гәүдәләндерү.
**ИЗОБРАЗИТЕЛЬНОЕ ИСКУССТВО – ТАСВИРИ СӘНГАТЬ** – дөнья күренешләрен яссылыкта, фәзадә(пространство)сурәтли торган пластик сәнгать. Төрләре: рәсем сәнгате, графика, сынлы сәнгать).
**ИЗУ – ИЗҮ** – татар хатын-кызларының дугасыман итеп төрле төстәге кәйтәннәр, тасмалар кыстырып тегелгән һәм тәңкәләр белән бизәлгән, күкрәкчә рәвешендәге тукымадан тегелгән борынгы бизәнү әйбере.
**ИМПРЕССИОНАЛИЗМ** – XIX гасырның икенче яртысында сәнгатьтә һәм әдәбиятта барлыкка килгән агым.
**ИНКРУСТАЦИЯ** – агачтан, сөяктән яки таштан ясалган әйберләргә чокып урнаштыру өчен төрле материалларданясалган бизәкләр.
**ИНТЕРЬЕР** – 1) җәмәгать, торак, сәнәгать биналарының эчке ягы.; 2) Һолландия һәм Франциянең XVI г. ахыры – XVII г., XIX г.ның беренче яртысында бидермайер һәм Русиядә А.Г.Венецианов мәктәбе рәсем сәнгатьләрендә үсеш алган тасвири сәнгать жанры.
**ИСКУССТВОВЕД – СӘНГАТЬ БЕЛГЕЧЕ.**
**ИСКУССТВОВЕДЕНИЕ – СӘНГАТЬ БЕЛЕМЕ.**
**КАЛЛИГРАФ – ХАТТАТ** – матур язу остасы, каллиграф, китап күчерү эше белән шөгыльләнүче.
**КАНИТЕЛЬ – УКА** – чигү, бигрәк тә алтын белән чигү өчен кулланыла торган үрелгән алтын яки көмеш җеп.

**КАНТ – КАЙМА** – рәсемнең кырыйларына кыса сыман ябыштырылган буй.
**КАОЛИН – АК БАЛЧЫК**.
**КАРТИНА** – мөстәкыйль мәгънәле һәм игътибар белән карап аңга килү өчен билгеләнгән, станокта ясалган тәмамланган төсле тасвири сәнгать әсәре.
**КАТАКАНА – ЯПОН ЯЗУЫ.**
**КЕРАМИКА – ТАШАЯК** – балчыклардан, аларның катнашмаларыннан ясалган һәм яндырылып ныгытылган әйберләр.
**КИТЧ** – “гүзәллек” һәм “нәфислек” турында гомуми кабул ителгән күзаллауларга туры килми торган әйберләр яки сәнгать әсәрләре. Китчка сентиментальлек, күтәренке патетика, төснең кычкырып торуы, ясалма электизм, декорның күплеге, кыйммәтле материалларга охшатып ясау хас.
**КЛАССИКА –** берәр ил яки чор сәнгатенең иң югары күтәрелгән, чәчәк аткан дәвере, сәнгать әсәрләренең үрнәк булырлыклары.
**КОЛЛАЖ** – тасвири сәнгатьтә техник алым; төсе һәм фактурасы белән җирлектән аерылып тора торган материалларны шушы җирлеккә ябыштыру; шулай ук шушы ысул белән башкарылган сәнгать әсәре. XX аеруча үсеш ала.
**КОЛОРИТ** – сәнгать әсәрләрендә, мәсәлән, картиналарда, буяуларның тон һәм төс тулылыгы ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәтләре.
**КОЛОСС** – бик зур һәйкәл.
**КОРПУСНАЯ ЖИВОПИСЬ – КОРПУСЛЫ РӘСЕМ ЯСАУ** – тыгыз, чагыштырмача калын, фактурасы рельефлы булган майлы буяу катламы белән рәсем ясау.
**КРАКЕЛЮР** – киндергә ясалган рәсемнәрдә, ш.у. фарфор һәм эмальдә буяу катламының чатнаган урыны.
**КУБИЗМ** – XX гасырның беренче чирегендә сынлы сәнгатькә хас модернистик агым: әйберләр дөньясын геометрик җисемнәр һәм фигураларның комбинациясе итеп күзаллап, шуны күләмле формада сурәтләү.
**КУФИ – КҮФИ** – хәрефләренең язылышлары һәм тоташулары туры һәм почмаклы-почмаклы булган гарәп язуы рәвешләре

төркеменең исеме. Ш.к. еш кына күфине турыпочмаклы яки геометрик язу буларак билгелиләр.

**ЛЕПНИНА – КҮПЕРТМӘ БИЗӘК** – биналарның фасадларындагы һәм эчке ягындагы гипстан, известьтән, бетоннан махсус формалардакоеп ясалган рельефлы бизәк.

**ЛИТОГРАФИЯ – ТАШБАСМА**

**ЛЮСТР** – керамика әйберләре өстен каплый торган металл яки сәдәф төсмере бирә торган күптөсле глазурь.

**МАЙОЛИКА** – балчыктан эшләнеп яндырылган һәм ялтыравык йөгертелгән яки буяу белән буялган әйбер.

**МАРИНИСТ – МАРИНАЧЫ** – диңгез күренешләре сурәтләнгән картиналар ясаучы рәссам.

**МАСТИКА** – вак скульптура әйберләре ясаганда кулланлы торган камырсыман куе масса.

**МАСТИХИН** – майлы буяулар белән рәсем ясау сәнгатендә кулланыла торган сыгылмалы нечкә кечкенә кашык.

**МИНИАТЮРА** – үзенең нәфислеге белән аерылып тора торган кечкенә картина.

**МОДЕРНИЗМ** – XIX гасыр ахыры һәм гамәли сәнгать өлкәсендәге юнәлеш.

**МОЗАИКА** – төрле төстәге пыялалардан, вак ташлардан, күннән ясалган нәфис бизәк яки рәсемнәр, сурәтләр.

**МОЗАИКА КОЖАНАЯ – КАЮЛЫ КҮН** – нәфис эшләнмәләрне, күбесенчә бизәкле аяк киемнәрен, төрле төстәге күн (сәхтиян, юфть) кисәкләрен каеп бизәү ысулы.

**МОНОЛИТ** – бөтен таш һәм шуннан ясалган һәйкәл, колонна.

**МРАМОР – МӘРМӘР**.

**НАБОЙКА – БАСМА** – уелган рельефлы агач такталардан яки кадаклы бакыр җыелмалы пластинадан кулдан бастырып бизәк төшерелгән тукыма.

**НАБРОСОК** – җиңелчә генә, карандаш белән тиз арада эшләп алынган рәсем.

**НАСХ – НӘСЕХ** – гарәп каллиграфиясендә авыш язу төрләренең иң борынгыларыннан берсе. Ачык, катлаулы булмаган, ваграк түгәрәк язу өслүбе.

**НАТУРА – ТАБИГЫЙ ҮРНӘК**.

**НАТЮРМОРТ** – чын көнкүреш мохитында урнаштырылган һәм бкртөтен төркемгә берләштерелгән җансыз әйберләрне күрсәткән тасвири сәнгать.
**ОГРАНКА – КЫРЛАУ** – “яктылык уены” эффекты бирү өчен ювелир ташының кырлары өсте буйлап симметрик рәвештә урнашкан күпкырлылыкның төзек геометрик яки симметриясез формасын шомартып һәм ялтыратып эшкәртү ысулы.
**ОЛЕОГРАФИЯ** – майлы буяулар белән ясалган рәсемне күчереп ясауга исәпләнгән күптөсле литография.
**ОРНАМЕНТИРЛОВАТЬ** – бизәк төшерегә.
**ОСНОВНЫЕ ЦВЕТА – ТӨП ТӨСЛӘР** – оптик катнашулары теләсә-нинди башка төс китереп чыгарырга мөмкинлек биргән өч төс. Төп төсләрнең рәсем сәнгатендә, полиграфия, кино - һәм фототехникада кулланыла торган төрле системалары бар. Табигый төсләр системасынна күбрәк сары, кызыл, зәңгәр төсләр туры килә, аларны бүтән төсләрне бер-берсе белән кушып ясап булмый, ләкин үзләре башка теләсә нинди төсне булдырырга нигез булып хезмәт итә. Сары, кызыл, һәм зәңгәр төсләр үзләренең өстәмә төсләре белән бергә спектр төсләрен барлыкка китерә.
**ОФОРМЛЕНИЕ** – нәкышләргә, бизәкләргә.
**ПАЛИТРА** – 1. Буяу тактасы; 2. Картинада төсләр гаммасы; 3. Рәссам куллана торган сәнгать чаралары җыелмасы.
**ПАННО** – 1. Диварның яки түшәмнең каймалап алып, скульптур бизәкләр белән яки рәсемнәр төшерелгән өлеше; 2. Стена яки түшәмнең бер өлешен бизәп торган картина яки рельеф.
**ПАНОРАМА** – түгәрәк бина стенасына урнаштырылган зур картина.
**ПАСТЕЛЬ** – 1. Рәсем ясау өчен йомшак буяу карандашлары. 2. Шул карандашлар белән ясалган рәсем.
**ПЕЙЗАЖ** – табигать күренешләре сурәтләнгән картина.
**ПЛАСТИКА** – сынлы сурәтләр ясау сәнгате.
**ПОРТРЕТ** – рәсем сәнгатендә, сынлы сәнгатьтә, графикада бер кешене яки төркемне сурәтли торган тасвири жанр төре.
**ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО – ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ** – көндәлек тормышта файдалан77ылган һәм шул ук вакытта эстетик нәфис сыйфатлары булган кирәк-яраклар ясау сәнгате.

**РАСТУШЕВКА – КАРАЛТУ** – карандаш, итальян карандашы, сангина, пастель һ.б.ш. белән ясалган сызыкларны һәм штрихларны кәгазь битенә ышкып буяу.
**РЕЛЬЕФ** – сурәте яссылыкта булган сынлы сәнгать төре: кабарынкы һәм батынкы була.
**РЕПРОДУКЦИЯ** – атаклы картиналарның күчермәсе.
**РИСУНОК – РӘСЕМ** – берәр әйбер өстендә коры яки сыек буяучы матдә белән кулдан төшерелгән сурәтләнеш.
**САНГИНА –** тышланмаган таяк-карандаш формасындагы рәсем ясау материалы һәм коралы.
**СВЕТОТЕНЬ** – яктылык-күләгәлек – фигураның яки предметның күләмен кабул итәргә мөмкинлек биргән төрле яктылыктагы төсләрнең бүленеше, ачык һәм караңгы төсләр градациясе.
**СКАНЬ – ҖЕПКЫР**, **БӨТЕРКӘ, СЕРКӘ, ЧЕЛТӘР БӨГҮ** (филигрань) – зәркән техникасы төре: алтын, көмеш, бакыр нәзек чыбыктан шомартып яки үрелеп эшләнгән нәкыш.
**СПЕКТРАЛЬНЫЕ ЦВЕТА** – **СПЕКТР ТӨСЛӘРЕ** – бергә оптик катнашкач, күзгә күренә торган көндезге яктылык тәшкил иткән кояш спектрының җиде төсе: кызыл, кызгылт-сары, сары, яшел, күк, зәңгәр, шәмәхә.
**СЮРРЕАЛИЗМ** – ХХ гасыр сәнгатендә авангардистик юнәлешнең бер тармагы.
**ТЕМПЕРА** – 1. Натураль эмульсияләрдә яки җилемдә әзерләнгән буяулар; 2. Шул буяулар белән ясалган сәнгать әсәре.
**ТРИПТИХ** – идеясе ягыннан берләштерелгән өч картина(сурәт).
**УЗОР – НӘКЫШ, БИЗӘК, ЧӘМЧӘ**.
**ФАКТУРА** – сәнгатьтә художество техникасының үзенчәлеге.
**ФОН – ҖИРЛЕК.**
**ФОРМА – ФОРМА, КАЛЫП, ШӘКЕЛ**.
**ФРЕСКА** – дымлы штукатурка өстенә суга изелгән буяу белән төшерелгән бизәк.
**ХОЛСТ** – 1. **КИНДЕР**; 2. Киндергә ясалган рәсем.
**ХУДОЖЕСТВЕННОЕ МАСТЕРСТВО** – сәнгать осталыгы.
**ХУДОЖЕСТВЕННОЕ ДАРОВАНИЕ** – рәссамлык сәләте.
**ЭСКИЗ** – картинаны ясар алдыннан эшләнгән кечкенә рәсемнәр.
**ЭСТАМП** – гравюрадан төшереп алынган сурәт.
**ЮВЕЛИР – ЗӘРКӘН, ЗӘРДАР.**

# ТӨСЛӘРНЕ БЕЛДЕРӘ ТОРГАН СЫЙФАТЛАРНЫҢ РУСЧА-ТАТАРЧА СҮЗЛЕГЕ

| | |
|---|---|
| Алый | ал, алсу |
| Багровый | куе кызыл, кучкыл кызыл |
| Бежевый | аксыл көрән |
| Белесый | аксыл |
| Белый | ак |
| Бледный | сыек, төссез, тонык |
| Бордовый | куе кызыл, чия кызыл |
| Бронзовый | җиз төсендә т |
| Бурый | көрән, коңгырт |
| Васильковый | зәңгәр күк |
| Вишневый | чия кызыл, карасу-кызыл |
| Голубой | күк |
| Дымчатый | төтен сыман |
| Желтый | сары |
| Зеленый | яшел |
| Золотистый | алтынсу |
| Каштановый | каштан төсле |
| Коричневый | көрән |
| Красный | кызыл |
| Кремовый | аксыл сары |
| Кумачовый | кызыл |
| Лазурный | аксыл күк |
| Лиловый | аксыл шәмәхә, миләүшә төсе |
| Малиновый | куе алсу |
| Матовый | аксыл, тонык |
| Оранжевый | кызгылт сары, әфлисун төсле |
| Палевый | сыек сары |
| Пурпуровый | җете кызыл |
| Розовый | алсу |
| Светло-синий | аксыл зәңгәр |

| | |
|---|---|
| Светлый | ачык төстәге |
| Серый | соры |
| Серо-зеленый | сорыяшел |
| Сизый | күгелҗем |
| Синий | зәңгәр |
| Сиреневый | аксыл шәмәхә |
| Сурик | кызгылт көрән |
| Темный | карасу, караңгы төстәге |
| Фиолетовый | шәмәхә |
| Черно-белый | аклы-каралы |
| Черный | кара |
| Электрик | зәңгәрсу-соры, күксел-соры |

# ОРФОГРАФИЯ СҮЗЛЕКЧӘСЕ

Афәрин, аһәңдәш, әгъза, әхлаклы, әһәмият, барельеф, берьюлы, бербөтен, бөек, бөтендөнья, бөтеркә, вазифа, вакыйга, васыять, вәгазь, вәгъдә, вәкаләтле, гамәли, гамьсез, гарәп, гөмбәзсыман, гөнаһ, гыйбарәт, гыйбрәт, гыйлем, гомумхалык, даһи, дәгъва, дәвер, данә, дәрман, дәүләтара, дәһшәтле, дөньякүләм, дөньяви, дикъкать, елъязма, җәза, җәмәгать, җәмгыять, җәрәхәт, җәүһәр, җәфа, җитди, җепкыр, җөрьәт, җинаять, зәвык, зәгыйфь, зәһәр, зәркән, зәңгәрсу, зәрдар, зиһен, зөбәрҗәт, игътибар, идарә, иҗади, иҗтимагый, икътисади, илаһи, илһам, ихтыяҗ, ихтирам, ихтыяр, ишарә, йогынты, йолдызнамә, йөзьеллык, кабилә, канәгатьсезлек, каһвә, кәгазь, кәсепчелек, кодрәт, коңгырт, коючы, көнбатыш, көнкүреш, көньяк, куәт, кустарьчылык, күгелҗем, күпкырлылык, күпьяклы, күфи, кыйммәт, массакүләм, матдә, маэмай, мәгариф, мәгарә, мәгълүмат, мәгърифәт, мәҗбүри, мәкаль, мәкалә, мәнфәгать, мәрхәмәт, мәсәл, мәсәлән, мәсьәлә, мәхәббәт, мәһабәт, мәшәкать, мәшгуль, меңьеллык, микъдар, милләтара, михнәт, миһербансызлык, мемориаль, монументаль, мохтаҗлык, мохит, мөгаен, мөгаллим, мөгамәлә, мөкиббән, мөлаем, мөнәсәбәт, мөрәҗәгать, мөстәкыйль, мөселман, мөлкәт, мөһим, мөһер, нәзакәтле, нәкыш, ниһаять, нотык, орнаменталь, охшаш, ошый, очраклылык, офык, өслүб, өчьяклы, өченчекөн, пөхтәлек, рөхсәт, сәнгать, сәнәгать, сәяхәтнамә, сөйкемле, сульяк, сурәт, табигать, таләпчәнлек, тасвирлама, тәвәккәл, тәгъбир, тәкәббер, тәкъдир, тәнкыйди, тәүфыйклы, тәэсир, төгәлсезлек, унъеллык, үзкыйммәт, үзсүзле, үзэшчән, фәкыйрь, фәкать, фәһем, хакимият, хакыйкать, хәрабә, холык, хосусый, хөкүмәт, хөкемдар, һәлакәт, һәрдаим, һөҗүм, һөнәр, һичкем, һәрьяклап, һәвәскәр, чынбарлык, шаһит, шәҗәрә, шәригать, шәрык, шәфкать, шәхес, шигырь, шагыйрь, шөгыль, шөһрәт, шөбһә, эзлекле, эчкерсезлек, эчпошыргыч, юньсез, юллама, ядкәр, яңабаштан, яшькелт.

# ЙОМГАК

Сүз сәнгате – халык байлыгы, ул аның тормышы, кызыксынулары, теләкләренә бәйле. Сәнгать, әдәбият телдән башка үсә алмый, чөнки тел – аралашу чарасы, көрәш коралы. Безнең илдә һәр милләт кешесе үз телендә белем алырга, җәмәгать оешмаларында сөйләшүләр алып барырга һәм җыелышларда үз телендә чыгыш ясарга хокуклы.

Кулланма татар телендә иркен аралашучы татар телле студентлар һәм татар телен чит тел буларак мәктәптә өйрәнеп килгән студентлар өчен төзелде.

Татар телле студентлар өчен тәкъдим ителгән биремнәр, (мәсәлән, һөнәре белән бәйле темаларга чыгышлар ясау, презентацияләр әзерләү, иншалар язу, текстны русчадан татарчага тәрҗемә итү һ.б.) һөнәри сөйләмне камилләштерү максатын күздә тота.

Текст ахырындагы грамматик биремнәр нигездә татар телен чит тел буларак мәктәптә өйрәнеп килгән рус телле студентлар өчен тәкъдим ителде. Мәгълүм булганча, телне өйрәнү – билгеле бер күләмдәге тел материалын, ягъни фонетик, лексик, грамматик материалны өйрәнү дигән сүз. Татар теленең лексик, фонетик, грамматик минимумнарын белми торып, чит телне өйрәнү шактый кыен, һәм моңа бирелгән вакытның чикле икәнен истә тотып, һәр студент билгеле бер күләмдә сүзләр, аваз күренешләре, грамматик кагыйдәләрне үзләштерергә һәм истә калдырырга тиеш була. Кулланмада бу эш һөнәргә ориентлаштырылган текстлар ярдәмендә тормышка ашырылды. Текстларны сайлаганда эстетик (татар теленең матурлыгын күрә, тоя белү) һәм эзлеклелек (алган белемнең даими рәвештә тулылана, байый баруы) принципларына нигезләндек, шулай ук студентларның телне белү дәрәҗәсен дә исәпкә алырга тырыштык.

Телне өйрәнү барышында әлеге телдә сөйләшүче җирле халыкның милли мәдәнияте һәм сәнгатен өйрәнүгә зур урын бирелергә тиеш. Милли мәдәниятнең иң югары казанышларының

берсен халык сәнгате әсәрләре тәшкил итә. Татар халкының милли сәнгать төрләре, милли киемнәре, танылган сәнгать осталары турындагы кызыклы мәгълүматларны үз эченә алган текстлар ярдәмендә студентларны татар сүз сәнгатенең асыл мәгънәсенә төшендерү – төп бурычларыбызның берсе. Татар халкының мәдәнияте, сәнгате, милли үзенчәлекләре белән таныштыру татар теленә һәм аның халкына булган хөрмәт хисләрен тагын да арттырыр дип ышанып калабыз.

# ТӨП ӘДӘБИЯТ

Фатхуллова К.С., Денмухаметова Э.Н. Обучение татарской речи. Казань: тат. кн. изд., 2016. 87 с.

Фәтхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Урта дәрәҗә. Казан: Хәтер, 2015. 147 б.

Фәтхуллова К.С., Юсупова Ә. Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшик//Давайте говорить по-татарски. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. 311 б.

# ӨСТӘМӘ ӘДӘБИЯТ

Ахметова Д.И. Проблема стилевого многообразия в ситуации современной художественной культуры. Казань: ИЯЛИ, 2014. 184 с.

Бхаскаран Л. Дизайн и время. Стили и направления в современном искусстве и архитектуре. М.: Арт-Родник, 2006. 257 с.

Валеева Д.К. Искусство Волжской Булгарии // Искусство народов СССР: В 10 томах. Т.3. М.1974. 178с. .

Валеева Д.К. Искусство Татарстана (20 век). К., 1999. 288 с.

Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. Казань, 1995. 146 с.

Валеевв Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969. 238 с.

Валиев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана К., 1974. 320 с.

Воронов Н. Развитие термина «дизайн» и его практики // Декоративное искусство. 2003. 238 с.

Воронов Н. В. Российский дизайн. Очерки истории отечественного дизайна. – М.: Союз дизайнеров России, 2001. I. 424 с., II. 392 с.

Глазычев В. Дизайн как он есть. Изд.2-е, доп. – М.: Издательство «Европа», 2006. –320 с.

Кривошеева Т.Н. Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. Казань, 2013. 254 с.

Михайлов С.М. История дизайна. М.: Союз дизайнеров России; т. I. 2000. 264 с., т. II. 2003. 392 с.

Михайлов С.М. История дизайна: В 2 т. М., 2002. 264 с.

Михайлов С.М., КулееваЛ.М. Основы дизайна. М., 2002. 288 с.

Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002. 175 с.

Рунге В.Ф. История дизайна, науки и техники. Учебное пособие. Издательство «Архитектура-С», 2008. 368 с.

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1998.

Соловьев Ю.Б. Моя жизнь в дизайне: Дизайн – это элегантность, эффективность и комфорт. М.: Союз дизайнеров России, 2004. 256 с.

Сулейманова Д.Н. Интерьер татарского дома: истоки и развитие. Казань: татар. кн. изд-во, 2010. 141 с.

Союз художников Татарстана, региональное отделение ВТОО «Союз художников России»: живопись, графика, скульптура, декоративно прикладное искусство, искусствоведен ие, монументальное искусство /авт.- сост. М.Кузнецов. Казань, 2008. 388 с.

Султанова Р.Р. Искусство новых городов Республики Татарстан. Казань, 2001. 164 с.

Султанова Р.Р. Художники Татарстана: справочник посвящается 75-летию Союза художников Татарстана / авт.-сост., авт.вст.ст. и разделов Р.Р. Султанова, др. разделов А.Р. Ильясова, Э.Ш. Салимзянова и др. Казань: Заман, 2011. 308 с.

Халитова Н.Д. Стили и форма средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казан: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

Хамматова В.В. Проектирование педагогической системы профессионального обучения дизайнеров. Казань, 2003. 96 с.

# СҮЗЛЕКЛӘР


Вагапова Ф.Г. Термины изобразительного искусства, архитектуры и искусства книги: толковый словарь = Тасвири сәнгать, архитектура һәм китап сәнгате атамалары: аңлатмалы сүзлек. Казань: “Магариф – Вакыт”, 2010. 231 с.

Донина Л.Н., Рамазанова Д.Б. Словник названий элементов татарского костюма: учеб. пособие. Казань, 2007. 120 с.

Русско–татарский словарь / Под ред. Ф.А.Ганиева. М.: Инсан, 1985. 784 с.

Русско–татарский словарь для работников библиотек, издательств и информационных служб / Отв. ред. Р.И.Валеев. Казань: Магариф, 1998. 176 с.

Словарь искусств. М.:Внешсигма, 1996. 534 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1981. 476 б.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: ТР ФАнең Татар энцикл. Ин-ты, 2002. 830 б.

Татарский энциклопедический словарь /гл. ред. М.Х.Хасанов. Казань: Ин-т Татар. энцикл. АН РТ, 1999. 703 б.

Татарча–русча сүзлек. М.: Сов. Энциклопедия, 1966. 324 б.

Татарча–русча уку–укыту сүзлеге. М.: Рус теле, 1991. 243 б.

Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан: ТР ФАнең Татар энцикл. Ин-ты, 2008. Т.1: А-В. 720 б. Т.2: Г-Й. 656 б.

## ИНТЕРНЕТ РЕСУРСЛАР

www.prav.tatar.ru
www.Kzn.ru
www.slovari.ru
www.Wikipedia.ru
http://mincult.tatarstan.ru/rus
http://rinfom.ru/kartinyi/zhivopis/
http://www.tatknigafund.ru
http://belem.ru/proektlar
http://www.filologia.su/sociolingvistikahttp://watan.su/

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

РФ – Россия Федерациясе
ТР – Татарстан Республикасы
Б.с. – бизәлеш сәнгате
һ.б.ш. – һәм башка шундыйлар
һ.б. – һәм башкалар
г. – гасыр
ш.у. – шулай ук

**ЭЧТӘЛЕК**

Кереш..........................................................................3

Беренче тема. Татар халкының сынлы сәнгате...................6
Икенче тема. Татар халкының бизәлеш сәнгате................14

Өченче тема. Татар халкының милли сәнгать төрләре.......23

Дүртенче тема. Татар халкының милли киемнәре............31

Бишенче тема. Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге. Танылган сәнгать осталары................................39

Кушымта.......................................................................49
Уку һәм аралашу өчен текстлар.......................................49
Сәнгатьле итеп сөйләү өчен шигырьләр............................68
Укып фикер алышу өчен мәкаль-әйтемнәр ......................72
Контроль эш биремнәре...................................................74
Реферат темалары...........................................................78
Сәнгать терминнары сүзлекчәсе.......................................79
Төсне белдерә торган сыйфатларның русча-татарча сүзлекчәсе...................................................................86
Орфография сүзлекчәсе...................................................89
Йомгак.........................................................................90
Әдәбият.......................................................................92
Сүзлекләр ....................................................................94
Интернет ресурслар........................................................95
Шартлы кыскартылмалар.................................................95